ГАЛИ ГАТАУЛЛИН

# Ишмөхәммәт хажи кыйссасы

УФА

2015

УДК
ББК

Гатауллин Г.Ш.

# Ишмөхәммәт хаҗи кыйссасы

**Җ**әяүләп х**аҗг**а барган,заманында Ислам дөньясында күренекле галим, дин белгече, Коръәнне матур итеп көйләп яттан укучы Коръән-хафиз буларак шөһрәт казанган Ишмөхәммәт Заитовның тормыш юлы, дини эшчәнлеге рәсми чыганаклар нигезендә тасвирлана.

ISBN с Гатауллин Г.Ш. 2015

Әссәламү галәйкүм вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

**“Җырлап - уйнап урадым, Күбәк авылы урамын”**

Бу дөньядан китәрбезләр,
Әҗәл суын эчербезләр.
Бер гамәлсез үләр булсак,
Кыяматтә нишләрбезләр.
Мөнәҗәт

Октябрь революциясеннән соң коммунистлар мәчет һәм мәдрәсәләрне җимерә, яба башлый, милли китапларны өеп яндыралар, зыялыларны, үз фикере булган галимнәрне милләтче, халык дошманы дип сөргенгә сөрәләр. Дин әһелләре дә аяныч язмышка дучар ителә, аларның күбесе репрессия корбаны булалар. Коммунистлар динне бетерергә, буыннар бәйләнешен өзәргә, Исламга хезмәт иткән шәхесләрнең исем - шәрифләрен халык хәтереннән җуеп ташларга тырыштыралар. Исеме тарих төпкелендә калдырылып онытылуга дучар ителгәннәр арасында Ишмөхәммәт Заитов та бар. Заманында Ишмөхәммәт Заит улы Идел - Урал төбәгендә, Ислам дөньясында киң танылу алган күренекле һәм абруйлы шәхес булган. Аның бөек мәгърифәтче Шиһабетдин Мәрҗәнидән югары бәя алуы, Ислам гыйлеме галиме, мөфти Ризаэтдин Фәхретдиннең Ишмөхәммәт хаҗиның дини эшчәнлеген җентекләп тикшерүе һәм өйрәнүе генә дә күп нәрсә турында сөйли.

Ишмөхәммәт 1750 елда (туган елы турында соңыннан да сүз булыр) Оренбург губернасы Бәләбәй өязенең Күбәк авылында (бүгенге Башкортостанның Бүздәк районы) туган. Шиһабетдин Мәрҗәни “Мөстәфадел- әхбар фи әхвәли Казан вә Болгар” (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланган хәбәрләр) исемле әсәрендә тарихи вакыйгаларда нинди дә булса роль уйнаган тирән белемле руханилар турында язганда китабының икенче томында Ишмөхәммәт Заитовка да аерым туктала һәм аның шәҗәрәсен дә китерә. “Ишмөхәммәд бине Заид бине Бикмөхәммәд бине Әлмөхәммәд бине Алуш бине Урманчы бине Чытырман бине Аяз бине Бишмәт әл-Кибәки”.”Биредә Ишмөхәммәднең унбер бабасы телгә

алына. Аларның сигезе-ягъни:Бишмәт, Аяз, Чытырман, Урманчы, Кызылбай, Колаш, Кулыш һәм Алуш- саф төрки исемнәр, ә инде Әлмөхәммәд, Бикмөхәммәд, Ишмөхәммәд исемнәре- төрки катыш гарәп, Заһид исә-саф гарәп исеме.Димәк, Ишмөхәммәднең әтисенең бабасы яшәгән чорда гына бу нәселдә (Ишмөхәммәд үзе 1750 елда туа,ата- бабаларына һәркайсына уртача 30 ар ел чигергәндә, 1650 еллар тирәсендә) гарәп исемнәре кушыла башлаган. Ә аңарчы кушылган исемнәр буенча бу нәсел кешеләре яшәгән урыннарда урманлык- чытырлык булган дип фараз кылырга мөмкин. Чөнки төрки халыкларда да,Көнчыгыштагы башка халыклардагы кебек үк, җир- су, күк йөзе, табигать күренешләренә бәйле исемнәр киң таралган булган һәм ул традиция XVII- XVIII гасырларгача сакланган”. (Мөстәфадел Әхбар… Баш сүз.Я.Г.Абдуллин, Ә.Н.Хәйруллин. Казан,1989)

Шиһабетдин Мәрҗәни язмасындагы “әл-Кибәки” сүзе-нисбә- Ишмөхәммәтнең акбабасы Бишмәтнең туган төбәген- Кибәкне күрсәтә. Кибәк авылы бүгенгедә Татарстанның Питрәч районына карый.Чал тарихлы әлеге авыл Казан ханлыгы чорыннан ук билгеле.

Мәгърифәтче, галим, дин белгече Ризаэтдин Фәхретдин дә үзенең “Асар” хезмәтендә Ишмөхәммәт хаҗиның дини эшчәнлеген ихтирам белән искә ала, аның тирән белемле дин белгече,галим, мөдәррис һәм мөгаллим икәнлеген раслый.

Риза Фәхретдин Ишмөхәммәт Заитовның тормыш юлын, дини эшчәнлеген өйрәнгәндә Күбәк авылына да килә.” Бу шәҗәрә, нәсел нәсәбенең кулында булган берничә нөсхәсеннән күчереп бу җирдә язылды”, -дип күрсәтә ул “Асар”да.- “Бәләбәй өязендә Күбәк авылында имам вә мөдәррис булып, 100 яшендә, 1256 елның зөлхиҗәсендә (1841 ел) вафат булган. Кабере өстендә булган ташы югалганга,яңадан икенче таш куелып,болай язылган: “Хаҗи, ахун Ишмөхәммәд Заидов, вафат булды 95 яшендә (Кәмәрия (Ай) ел хисабы белән 100 яшь ахыры була), 1 февраль,1841 елда,яздым мин Габделлатыйф Ишмөхәммәд угылы 1870 ел 3 сентябрьдә”.

“Ишмөхәммәд хәзрәтләре яшь вакытында укый-яза белгәннәрдән булмый,- дип дәвам итә Р.Фәхретдин.-Авылдагы гади халык балалары илә берлектә вакытында эшләп,вакытында рәхәт чигеп, көн уздыра торган булган. Җырларга

маһирлыгы сәбәбеннән, һәртөрле мәҗлесләргә чакырылып, төрле кешеләрнең кәефләрен күтәрә торган булган.Кыска вакыт эчендә скрипка уйнарга өйрәнеп, үзе кебекләр арасында кызыгырлык бу ике һөнәрне бергә туплаган. Шушы хәлендә яшәгәндә өйләнгән вә 22 яшендә, көннәрнең берендә, авылдан югалган."

Нигә Ишмөхәммәт, һич көтмәгәндә, беркемгә берни әйтми, туган авылы Күбәктән чыгып киткән? Ни кергән аның җырга,моңга бай күңеленә? Ишмөхәммәтнең һич көтелмәгән әлеге адымы сәер бер хәл була. Күбәк, пошаманга төшеп, шым кала-егетнең моңы авыл өстенә сирпелми, скрипка кыллары күңелләрне сызмый инде хәзер.

Ризаэтдин Фәхретдинов: "Биография-кешенең тормыш юлын яктырту ул. Ләкин шул ук вакыт та һәр шәхси биография тарихыбызның бер бите булып тора,"-дип әйткән. Шушы фикергә нигезләнеп Ишмөхәммәтне авылдан чыгып китәргә этәргән алшартларны аңлау, ачыклау өчен һәм соңыннан аның күренекле шәхес булып китүенә булышлык иткән Русиядәге тарихи- сәяси мохитне искә төшерик, Исламның биш баганасы- төп кагыйдәләре турындагы тәгълиматне күңелләребездә яңартыйк.

## Ислам- яшәү рәвеше

Ислам, иман гына
Нурландыра күңел
галәмен.
Госман Садә

Ислам дине мөселман халкында иң дәрәҗәле урын биләгән, ә 1552 елда Иван Грозный Казанны яулап алгач мөселманнар күргән золымлыкларның иге-чиге булмый: бөтен җирдә суеш-үтереш, канга батырыш өстенә дингә каршы да сугыш игълан ителә: мәчет,мәдрәсәләр җимерелеп алар урынына чиркәү һәм монастырьлар салына, Изге Коръән, башка дини китаплар өеп яндырылалар.

Явыз Иван явы ясаган вәхшилек турында халкыбызның бөек шәхесе Әхмәт Зәки Вәлиди түбәндәге сүзләрне язып калдырды: ”Иван IV динсез дип фикер йөрткән мөселман ханнарының каберләрен туздырып, сөякләрен алып ташлатты. Мөселманнарның, казанлыларның үз диненә каршы дип тапкан гыйльми әсәрләрен, китапларын, язуларын-берсен дә сәламәт көйгә алып калмады. Ул заманда белем җәһәтеннән бик түбән урында торган рус гаскәре,динсез дип уйланган казанлыларның әсәрләрен бер дә кызганмады. Шулай итеп Иван Грозныйның дини фанатизмы тәэсирендә безгә тарихыбызны, үткәннәребезне күрсәтерлек бернәрсә дә сәламәт калмады.” (Ризаэтдин Фәхретдин.Казан ханнары. Казан,1995.174,175 б.б.)

Иван Грозный Казан ханлыгын яулап алгач Идел-Урал халыкларын руслаштыру- чукындыру башлана. Хокуксызлыкка, милли һәм социаль изүгә түзә алмаган, Исламга тугры кешеләр бай табигатьле, яшәр өчен ифрат уңай Урал ягына кача, күченә башлыйлар.“Нәкъ шушы вакыт Идел буйларыннан көнчыгышка халык агышы көчәя.1719 елда, мәсәлән, Казан төбәгендә 19932 крестьян йорты бушап кала. (Социалистик Татарстан.1990)”.“Алдар Күчем явы башланганчы башкорт далаларында яшәгән халыкның күләме 35-40 меңнән дә артык түгел иде. Нигездә Казан һәм Сембер өязләреннән качып киткән татарлар килеп кушылгач, хәзер андагы халык саны 100 мең чиген дә узып китте,-“ дип яза

Казан губернаторы А.Волынский 1730 елда сенатка.(История Татарии в документах и материалах.М.1937)

Башкорт вотчинникларының биләмәсенә язма килешү нигезендә яки ансыз гына төпләнүчеләрне “припущенник” дип атаганнар. “История Башкирской АССР” китабында (Уфа,1972) түбәндәге юллар бар (13,14 б.б.):”Нерусских припущенников именовали тептярями и бобылями. К припущенникам относились также мишари или мещеряки- татарское племя, переселившиеся в Башкирию после ее присоединения к русскому государству. За пользование землей припущенники платили башкирам оброк или принимали участие в уплате ясака и несений гужевой повинности”.

Әлеге өзектә очраган “типтәр” атамасына аңлатма бирү өчен күренекле сәяси эшмәкәр, галим Зәки Вәлиди әсәреннән өзек китерү урынлы булыр.

“…Четвертая группа состоит из беглых татар (иначе тептяр, что означает “занесенный в тетрадь”), буляр (булгар), мишар и чувашей, мусульман вынужденных бежать в Башкортостан из Поволжской Булгарии, Казани после того, как русские захватили их земли. Этих беглецов с запада, из Казанского Ханства русские назвали “башкирскими припущенниками”, т.е.новобашкирами, принятыми башкирами на их исконные земли”. (Заки Валиди Тоган. Воспоминания. Уфа. ” Китап”, 1994г.стр.8).

Казан ханлыгында тарихның кара битләре язылган дәвердә үз диненнән, иманыннан ваз кичәргә теләмәгән Ишмөхәммәтнең борынгы бабалары туган төбәкләре Кибәкне калдырып башкорт ягына күченәләр һәм Күбәк авылында тамыр җибәрәләр. Ишмөхәммәт Заитов рәсми язмаларда “башкорт, типтәр даирәсеннән”дип искә алына.

1740 елда чукындыру конторасы оештырыла, ләкин әлеге сәясәт көткән нәтиҗәләрне бирми, моңа каршы халыкның ачуы гына кабарып күп урыннарда дин байрагы астында баш күтәрүләр дә булып тора.

Вакыт үтү белән патша хөкүмәте бу сәясәтеннән чигенергә һәм мөселман руханилары белән уртак тел табу юлларын эзләргә мәҗбүр була.

1762 елда Рәсәй тәхетенә Софья Фредерика Августа –Екатерина П утыргач мөселманнар тормышында азмы-күпме уңай үзгәрешләр күзәтелә башлый:1764

елда чукындыру конторалары ябыла, дәүләт мөселманнарның дини оешмалары эшенә катышмый башлый.

1767 елның яз, җәй айларында Екатерина П Идел буйлап сәяхәткә чыга һәм Болгарда, Казанда була.

Патшабикәнең рөхсәте белән 1771 елда Казанда Апанай мәчете ачыла.Екатерина П-нең 1773 елның 17 июнендә игълан ителгән указы нигезендә Рәсәй империясендә яшәгән халыкларның үз дини йолаларын үтәүләренә архиерейларның катышуларына чик куела, анда һәр халык үз динен тотарга ирекле, Алла җирдәге бөтен динне дә кабул итә, дип әйтелә.

Патшабикәнең 1783 елдагы указы мөселманнарга ахуннарны үзләренә сайларга рөхсәт итә. Әлеге указга кадәр муллалар күбрәк Урта Азия ягыннан чакырылган була. Хәзер инде дәүләт дин әһелләре итеп дәүләткә хезмәт итәрдәй ышанычлы шәхесләрне күрсәтә, муллалар санын көйли ала.1784 елда татар морзаларына, башкорт старшиналарына дворян хокукы бирелә;мөселман сәүдәгәрләренә Төркстан, Иран, Индия, Кытай белән сәүдә эшендә ташламалар игълан ителә. 1785 елда Рәсәй территориясендәге һәр дингә ирек бирелеп мөселманнарның хокукларын саклау, аларны көйләү турында нигезләмә гамәлгә керә.

1788 елның 22 сентябрендә Екатерина II Уфада диния нәзарәте оештыру турында указ игълан итә. Моңа кадәр матбугатта бик сирәк күренгән әлеге фәрман белән тулырак танышу урынлы булыр.

**1788г.сентября 22.**

**Указ Екатерины II Симбирскому и Уфимскому генерал- губернатору барону Игельстрому об учреждении в Уфе Духовного Собрания Магометанского закона.**

Приняв за благо предоставление ваше, чтоб Мулл и прочие духовные чины Магометанского закона между народами оный в Империи Нашей исповедующими, определялись не инако, как по ученическим им надлежащего испытания и с утверждением Наместничнского Правления, повелеваем вам произвесть сие в действо, и в следствие того учредить в Уфе духовное собрание Магометанского закона, которое, имея в ведомстве своем всех духовных чинов

того закона, в разных губерниях пребывающих, исключая Таврический области, где особое есть Духовное Управление, в случае надобности определить их куда-либо вновь, сии люди были испытываемы, и не инако определяемы, как когда признаны будут достойными: со стороны же наших Генерал-Губернаторов, правящих ту должность, в отсутствии же их Губернаторов, наблюдать, дабы к исправлению духовных должностей Магометанского закона употребляемы были люди в верности надежные и доброго поведения. В духовном собрании помянутом председательствовать первому Ахуну Мухамет Джан Гусейну, коего Мы Всемилостевейше жалуем Муфтием с произвождением ему жалованья по 1500 рублей в год, и с ним заседать 2 или 3 Мулл из Казанских татар, в верности к Нам и в добропорядочном поведении их испытанным, с жалованьем по 120 рублей на год; о чем предоставляем вам снестись с Генерал-губернаторами и правящими ту должность тех губерний, в коих народы Магометанской веры обитают.

Императрица Екатерина П-нең 1787 елдагы указы нигезендә Санкт-Петербургта Коръәннең тулы тексты басыла һәм ул мөселманнарга бушлай таратыла. Шул ук указы белән Әби патша дәүләт исәбенә мәчетләр төзергә рөхсәт бирә. Аның күрсәтмәсе нигезендә 1789 елның 4 декабрендә Уфада Диния нәзарәте эшли башлый. Патша хөкүмәте үз максатларын иң беренче урынга куя һәм ул бик күп урыннарда эшләп килүче аерым мәхәлләләрне Диния нәзарәтенә берләштереп әлеге җирләрдә дин байрагы астында үзенең колонизаторлык сәясәтен тормышка ашырырга тели.Әби патша Диния нәзарәтенең структурасын да, эш максатларын да үзе билгели, моңарчы булмаган мөфти дәрәҗәсен кертә.

Шиһабетдин Мәрҗәни билгеләвенчә, Диния нәзарәтенә, имтихан алып, ахуннарны, мөхтәсиб, мөдәррис, хатыйб, имамнарны билгеләү, мәчет төзергә рөхсәт бирү, шәригать кануннарының үтәлешен тикшерү хокукы бирелә.

1789-1798 елларда Санкт-Петербургта Коръәннең биш басмасы чыга.

1796-1802 елларда Диния нәзарәте Оренбургта була, ә аннары соң яңадан Уфага күчерелә.

XVIII гасырның ахырында империядә яшәгән мөселманнарга үзәк властьның йогынтысы көчәя, Русиядә яшәүче мөселман сәүдәгәрләре күрше

мөселман илләре арасында арадашчы булып Русиянең Урта Азияга үтеп керүенә булышлык итәләр. Мөселманнарны күпләп Русия армиясенә,флотына хезмәткә алалар, армиядә мулла, ахун, мөәзин вазыйфалары булдырыла.

Моңа кадәр рухи изелүгә дучар булган дин тотучы мөселманнарга әлеге үзгәрешләр азмы-күпме иркенлек биргән һәм аларга Исламның биш баганасы булган төп дини кагыйдәләрне башкару өчен азмы-күпме шартлар тудырыла.

Исламның биш баганасы,ягъни төп биш кагыйдәсе бар. Беренчесе-ул Аллаһның берлеген, барлыгын һәм Мөхәммәд (с.г.в)нең Аның илчесе, пәйгамбәре булуын тану, ягъни: “Ләә Илаһә иллә Аллаһу, Мөхәммәдүр расүлүллаһ”,- дип әйтү, шәһадәт бирү.

Исламның икенче баганасы – намаз. Ул безгә Мөхәммәд (с.г.в)аша Мигъраҗда йөкләтелә. Намаз, башка баганалардан аермалы буларак, Җәбраил фәрештә аркылы түгел, бәлки Аллаһыдан Пәйгамбәребез (с.г.в.) гә турыдан-туры йөкләтелә. Шушы үзе генә дә намазның никадәр әһәмиятле гамәл икәнен күрсәтә. Намаз ул- Алланың рәхмәте. Ул Аны яраткан колларына гына бирә.

Исламның өченче баганасы- ураза. Алла Тәгалә: “Тәкъвалыгыгыз артсын өчен Рамазан аенда ураза тоту сезгә фарыз кылынды”,- ди һәм ураза тотуның фарызлыгын гына түгел, бәлки фарызлыгының сәбәбен дә аңлата.

Аның сәбәбе- тәкъвалыкны арттыру. Тәкъвалык ул-Алла Тәгаләгә булган ышаныч, Аны ярату, Аның җәннәтен өмет итү һәм Аның җәзасыннан курку. Ураза тоткан кеше рамазан аеннан үзгәреп, тәне пакъләнеп, сихәтләнеп чыга, иманы ныгый.

Исламның дүртенче баганасы-зәкят. Алла намаз укуны фарыз итеп йөкләү белән беррәттән зәкят бирүне дә фарыз итеп йөкли. (“Әй,мөэминнәр, намазларны вакытында укыгыз, зәкятләрегезне бирегез һәм Расүлгә буйсыныгыз, шаять, Аллаһыдан рәхмәт ителерсез”).

Дөнья үзенең бөтен малы- байлыгы белән Алла Тәгаләнеке.Алла Тәгалә безгә мал бирә, әмма бер шарт куя: кулында булган малының шәригать белгеләгән күләмдәге бер өлешен зәкят итеп, зәкят малы бирелергә тиешле кешеләргә бирү. Алла зәкятнең мәҗбүрилеген, әһәмиятен аңлатып кына калмый, ул зәкят бирүчеләргә зур әҗерләр вәгъдә итеп, Коръән- Кәримдә әйтә:” Алар намазларын

үтәрләр, зәкят сәдакаларын бирерләр, Алла Тәгаләгә һәм әхирәт көненә ышанырлар. Әнә шуларга тиздән олы әҗерне- җәннәтне бирербез.”

Зәкят кешенең малын гына пакъләп калмый, ул аның күңелен чистарта, саранлык хисләрен бетерә, җәмгыятьтә мохтаҗларның ихтыяҗларын канәгатьләндерә. Зәкят биреп, кеше үз малының бәрәкәтен саклый, матди байлык аңа бәхет китерә.

Исламның бишенче баганасы-хаҗ. Хаҗ дип Мәккәи Мөкәррәмәгә барып, шәригатьтә күрсәтелгән рәвештә билгеле бер гамәлләрне кылу белән бергә Кәгъбәтулланы зиярат кылуга әйтелә. Алла Коръән- Кәримдә әйтә:”Көче җиткән кешеләргә Аллаһыга гыйбадәт кылу өчен хаҗ кылу фарыз кылынды”.

Азат, акыллы, сәламәт,сәфәре тәмамланганчы юл чыгымнарына һәм үзенең гаиләсенең яшәешенә дә җитәрлек малы булган мөселман кеше үз гомерендә бер мәртәбә билгеләнгән көннәрдә, шәригатьтә билгеләнгән рәвештә, тиешле тәртип белән хаҗ кылырга тиеш.

Хаҗ гамәлләрен үтәү тәртибе атабыз Ибраһимнан калган. Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа (с.г.в.) күрсәтеп, өйрәтеп калдырган хаҗ кылу рәвеше- ул асылда Ибраһим кылган хаҗ.

Мәккә җире-изге җир. Мәккәдә Пәйгамбәребез туган, яшәгән, монда аңа Коръән иңә башлаган. Аллаһы Тәгалә Мәккәне ахырзаманга хәтле имин итеп саклаячагын хәбәр итә. Мәккәи Мөкәррәмәнең иллегә якын исеме бар. Мәгънәләре: куркынычсыз шәһәр, шәһәрләр шәһәре, Аллаһ йорты.

Монда Коръән иңә башлаган Хива тавы бар. Пәйгамбәребез вәхий килер алдыннан шул тау куышында атналап торган, ризык, су алырга гына төшә торган була. Шунда аңа Аллаһыдан беренче хәбәр җиткерелә, Коръәннең беренче: ”Укы” ,-дигән сүзен ишеткән.

Аллаһы Тәгалә Ибраһим Галәйһиссәлләмгә:”Кешеләрне хаҗга чакырып хәбәр бир, җәяү йөреп сиңа килерләр. Арык дөяләргә атланып килерләр, ул дөяләр ерак юлларның һәрберсеннән килерләр”, -ди. Ибраһим Галәйһиссәлләм: ”Минем тавышым дөнья буйлап тарала алса иде!”-ди. Аллаһы Тәгалә: ”Синең эшең чакыру, мин синең чакыруны теләсә кая, хәтта җир читенә дә җиткерермен!” -дип җавап бирә.

Екатерина II хакимлек иткән чорда дин тотучы мөселманнарга бирелгән мөмкинчелекләр Ишмөхәмматкә ныклы карарга килергә булышлык иткәндер дә инде-күңеле белән Исламга тартылган Ишмөхәммәт, Исламның бер баганасы булган хаҗ кылу сәфәренә җәяүләп чыгып китә.

***

Ул чорда хаҗ сәфәре бик җиңелдән булмый, хатта берничә елга сузылган ул,булачак хаҗиларга төрле куркынычлар янаган.

Ишмөхәммәт, күп михнәтләр кичереп, Сәмәрканд, Бохара аркылы Әфганстанга барып җитә. Кабул, Пешавар һәм Бомбейны үткәч, Кызыл диңгезне пароход та кичеп, Җиддә шәһәренә килә. Монда хаҗга баручыларны "әмир әл-хаҗ"- махсус юл күрсәтүчеләр көтеп торганнар. Алар җитәкчелегендә хаҗ кылучылар, караван белән, Мәккәгә юл тоталар һәм ун сәгатьтән соң килеп җитеп ялга тукталганнар. Ялдан соң караван Мәдинәгә юл тота. Изге җиргә кадәр тагы да ун көнләп барырга кирәк булган.

Чүлдә ком бураны котырган чакларда адашып та йөриләр алар. Авырлыкларны күтәрә алмый һәм төрле йогышлы авырулардан юлда үлеп калучылар да була.

Гарәбстан җиренә аяк басу белән хаҗ кылучылар махсус кием-ихрам кияләр. Минә үзәнлегенә барганда өч тапкыр, символик төстә, шайтаннарга таш ата-ата йөгерәләр һәм Минә үзәнлегендә тукталып корбанга үгез чалалар-мәҗлес уздырыла. Аннары Кәгъбәгә килеп җитеп аны җиде тапкыр әйләнеп чыгалар, кара ташны үбәләр. Шуннан соң хаҗ кылучылар "Ибраһим таянган таш" янына киләләр. Сафа һәм Мәрвә таулары арасын йөгереп узгач, "изге" Зәмзәм суын эчәләр, намаз укыйлар. Әлеге йолаларны үтәгән кеше "хаҗи" исеменә лаек була.

Кәгъбә -мөселманнарның Мәккәдәге изге йорты, Әл-Мәсҗид әл-Хәрәм, ягъни изге мәчет.Ул соры таштан эшләнгән яссы түбәле, дүрт почмаклы бина, озынлыгы 13, иңе 12 метр, биеклеге 15 метр тәшкил итә. Аның эче буш, ишеге мәйдан өслегеннән 2 метр биеклектә, шуңа күрә аның эченә баскыч куеп кына керергә мөмкин. Кәгъбәнең бер як стенасына тышкы яктан "кара таш" кертеп урнаштырылган. Кәгъбәдә саклана торган әлеге кара таш, метеорит, цемент, сумала һәм ком катнашмасыннан эшләнгән кара төстәге кысага төрле зурлыктагы

15 метеорит урнаштырылган. Карасу-көрән төстәге бу ташлар аксыл һәм саргылт вак бөртекләр белән чуарланган. “Кара таш”- мөселманнар өчен “изге таш” булып санала.

Мәккәдә Кәгъбә мәчете ишегалдында зәмзәм коесы бар. Аның суы бераз тозлы һәм әчкелтем. Мөселманнар зәмзәм суын тәнгә дә, җанга да шифалы дип саныйлар, аны һәртөрле авырулардан дәвалану өчен эчәләр. Хаҗилар аны,савытларга тутырып, үз илләренә алып кайтып китәләр.

Пәйгамбәребез туган, яшәгән, аңа вәхий килгән һәм Коръән иңә башлаган Мәккә мөселман булмаган кешеләр өчен 14 гасыр буена ябык шәһәр санала. Дөньяның зур сере, Аллаһының хикмәтләре күпләрне кызыксындыра. Беренчеләрдән булып 1503 елда хаҗилар белән берлектә Италия сәяхәтчесе Лодовико ди Вартема  үтеп керә.

Телне, тарихны өйрәнеп, бик күп Европа телләренә тәрҗемә ителгән юлъязма-китап чыгара.

Үзләренең гомерләрен куркыныч астына куеп, телне, Коръәнне өйрәнеп, исән  -сау Мәккәгә -Мәдинәгә барып, икешәр, өчәр томлы китаплар чыгаручы, дөньякүләм дан алган кешеләр ул гына түгел.

Ричард Бертон-офицер –разведчик, дипломат, сәяхәтче -1853 елда 32 яшендә хаҗилар белән юлга чыга. Ул чакларда хаҗ кылырга баручыларга бик куркыныч була. Еш кына юлбасарлар һөҗүм итә.Ач, ялангач калдырып талыйлар. Ричард исән-имин Мәккә шәһәренә барып җитә.Күргәннәре турында өч томлы китап язып бастыра, дөньяга тарата.

Ишмөхәммәт хаҗ вакытында төрле илләрдән килгән күп мөселманнар белән аралаша, аларның гореф-гадәтләре белән таныша.

Мөселманнар өчен Хаҗ кылу гамәле барлыкка килгәннән бирле аның тәртибе, үтәлеше үзгәрмәгән. Аерма бары тик хаҗга бару ысулларында гына. Борынгыда җәяүләп җиде мең чакрым юл үтеп Ишмөхәммәт мөселманнарның Изге җиренә барып ирешсә, бүген инде анда автобусларда, самолетларда очып кына баралар. Булачак хаҗилар өчен бар уңайлыклар да тудырылган. Ләкин барыбер хаҗ гыйбадәте авыр, мәшәкатьле, әмма әҗер-савабы күп булган гыйбадәт булып кала.Хаҗга баргач алган кичерешләрне, тәэссоратләрне бары тик

үзе  хаҗ кылган кеше генә белә. Менә шуның өчен, хажда Ишмөхәммәтнең ни күргәннәрен, ни кылганнарын күңелләребездә яңартыр өчен, “Хаҗ маҗаралары”исемле китаптан өзекләр китерелә. Аны язучы Идрис хәзрәт Галяутдин инде күп еллар буена Татарстан мөселманнарының диния нәзарәте канаты астында эшләүче “Идел хаҗ” оешмасы аша хаҗга баручыларга җитәкче булып бара.

***Уфада хаҗиларның хаҗга әзерләнүләре***

Хаҗга баручы мөселманнарның туплану урыны Уфа Диния нәзарәтендә булды.Ул чагында хаж сәфәре май-июнь тирәсендәрәк булган вакытлар.1992 елда хаҗга баручыларның саны 300ләп кеше булды.Шуның яртысы үзбәкләр,таҗиклар,калганнары татар һәм башкорт халкы иде.

Хаҗ кылырга ниятләгән юлдашларымның кайберләре ерак җирләрдән:Үзбәкстаннан ,Таҗикстаннан бер атна-ун көн алдан Уфага килеп төшкәннәр икән.

Менә инде китәр вакытлары да якынлашты. Самолетларның аэропортка килүләре хакындагы хәбәр халык арасында яшен тизлегендә таралган, кичкырын йокы вакыты якынлашкан булса да, безгә ихрамга керергә дигән әмер булды. Бермәлне бөтен ир-ат мөселманнарның ихрам киемнәре кигәнлекләрен күрдем. Әле минем ул вакытта ихрамны кулыма тотканым да, гомеремдә бер тапкыр бәйләп караганым да юк иде.

Ихрам-ике кисәк ак тукымадан торучы махсус кием:беренчесен янбаш тирәли урыйлар (изар), икенчесен иңсәләргә каплыйлар (рида). Бу вакытта күңелең изге ният белән тулган булырга тиеш. Хатын-кыз үз киемендә кала. Барча хаҗилар шул ихрамны кигәннәр, гүя ки алар ак күгәрченнәр шикелле булганнар. Мөхәммәд с.г.в.с. хаҗны гомрәдән башлаган. Без дә юлда ихрамга керә алмабыз дип Уфа шәһәрендә үк ихрамга кердек, һәм расулебезгә охшап гомрәдән башладык. Кече хаҗ гамәлләре бишәү:

1.Ихрам киемнәрен кию.

2.Тәваф кылу.

3.Сәгый кылу.

4.Чәч кыру.

5.Ихрам халәтеннән чыгу.

Мин дә соңга калмыйм тагын дип, тизрәк ихрам баглау турында кайгырта башладым. Хәстәрләп куйган ике кисәк ак тукыманы алып, ваннага кереп, тиешле дәрәҗәдә пакьләнеп, ак ихрамнарымны кияргә тотындым. Әмма ихрамны баглый алмаганлыктан остазым ТәлгатьТаҗетдинга мөрәҗәгать иттем. Мөфти хәзрәтләре мине ихрам багларга өйрәтте. Аллаһы Тәгалә изгелеккә өйрәткән остазларыбызның барысын да бәхетле итсә иде.

Беренче самолет белән очучы кешеләр, ихрамнарны баглап, хәстәрләнеп куелган автобусларга утырдык. Моңа кадәр барысы да яхшы гына барды.Без Аллаһының йортына барабыз, анда барысы да яхшы булыр дип өметләнеп куанышабыз.

**Һава аланында**

Һава аланында безне туганнарыбыз, якын дусларыбыз озатып калдылар. Уфа аэропортында бернинди авырлык тоймадык, барыбыз да җиңел генә чикне үтеп, очкычларга утырдык һәм, Аллаһыга тәвәккәл кылып,белгән догаларыбызны укып, “Ләббәйкә” догасын кабатлый-кабатлый Сочи аэропортына килеп төштек.

Сочи шәһәрендә никадәрле генә арыган булсак та хаҗга баручы мөселманнарны тынычландыру максатыннан һәм анда баргач ничек итеп хаҗ гамәлен кылырга кирәклеген өйрәтү нияте белән, очучылардан рөхсәт алып, микрофонны кулыма алдым. Аллаһы Тәгаләдән ярдәм сорасаң, ул үзенең колларына ярдәмне бирәм дип вәгъдә кылган. Мин дә хаҗиларның иманнары көчәйсен, тәкъвалыклары артсын дигән изге нияттән хаҗ сәфәренә чыккан юлдашларыма вәгазь-нәсыйхәтләр сөйләдем. Сочидан соң тагын дүрт сәгать тирәсе очып , **Җ**иддә шәһәренә килеп төштек.Ул Мәккәдән 70 километр чамасы ераклыкта,Кызыл диңгез ярында урнашкан шәһәр.

Аллаһының рәхмәт киң. Юлда авыр булса да, Мәккәгә килеп життек.

**Безнең бәйтуллаһка беренче мәртәбә аяк басуыбыз**

Аллаһының рәхмәте киң. Менә без дә теләкләребезгә ирештек. Барыбыз да азаплана-азаплана булса да Раббыбыз Аллаһының йортына килеп җиттек.Без Аллаһының йортына килеп җиткәнче”Тәлбияләребезне”, зекерләребезне көчебез җиткәнчә кабатлый-кабатлый бардык. Ул менә болай әйтелә:

“Йә Аллаһ, менә мин Синең каршыңда! Менә мин Синең каршыңда! Менә мин Синең каршыңда! Сиңа иптәш булырлык бернинди дә зат юк! Барча мактау сиңа гына, барлык нигъмәт һәм хөкем Синең кулыңда гына! Сиңа иптәш булырлык бернинди дә зат юк!

Бәйтуллаһ янына килеп житкәннән соң мин тагын халыкны туктатып тагын аларга артларына, ян-якларныа карарга һәм Хәрәм мәчетенең ишекләренә күз салырга куштым. Андагы ишекләрнең барысы да номерланган, алар шул номерларга карап ишек номерларын да исләрендә калдырдылар. Соңыннан мин аларга Хәрәм мәчетенә кергәннән соң нәрсәләр эшләргә кирәклеге хакында тагын бер кат исләренә төшереп вәгазьләдем. Мәсҗид-л-Хәрәмгә кергән вакытта менә бу дога укыла:

“Сыгынамын, Бөек булган Аллаһы Тәгаләгә, Аның күркәм йөзенә, Аның мәңгелек хөкеменә ләгънәт кылынган шайтаннан! Аллаһының исеме белән! Аллаһының рәсүленә салават- шәрифләр, сәламнәр булсын иде!

Йә раббым! Миңа Үзеңнең рәхмәт капкаларыңны ачсаң иде!”-дип булачак хаҗилар ошбу доганы укый-укый Аллаһының мөбәрәк булган йортына аяк басалар.Гыйбадәт кылганнан соң җыелышу өчен очрашу урынын билгеләп куйдым.

Алдыбызда нинди генә киртәләр булмасын, барысын да Аллаһының рәхмәте белән үтеп чыгып, Аллаһының мөбарәк йортына килеп җиттек. Бездән алдан килгән хаҗиларның барысының да гыйбадәттә икәнлекләрен күрдек. Кайберләре намаз укый,кайберләре кулларына Коръән тотып Коръән укый, кайберләре Сафа белән Мәрвә арасында йөгерә, бәгъзеләре байтуллаһны тәваф кыла. Безнең иң беренче гыйбадәтебез җиде мәртәбә тәваф кылу иде. **Кәгъбәтулаһны күрү белән хаҗилар кулларын күтәреп:**

“Йә Раббым! Син Үзең Тынычлыксың һәм Синнән бар җиргә тынычлык иңә! Безне, Раббым, тынычлык белән сәламләсәң иде! Йә Раббым! Бу Йорт тагын да мөбарәк булса иде! Аңа тагын да зуррак дәрәҗә, дан һәм ихтирам булса иде! Шушы Йортка, аны зурлап һәм данлап, хаҗ яки гомрә кылган кешеләргә тагын да күбрәк олыласыннар һәм алар тагын да тәкъварак булса иделәр!-дип дога

кылалар. Без дә белгәннәребезне укып барыбыз да ошбу изге гамәлне үтәргә тотындык.

Барысы да тәваф кылалар. **Тәвафны башлаганда хаҗи:** Йә Аллаһ, сиңа иман китереп, Китабыңның (Коръәни Кәрим) дөреслеген танып, Сиңа биргән вәгъдәмне үтәү йөзеннән, Мөхәммәт пәйгамбәрнең сөннәте буенча, Аллаһының аңа сәламнәре һәм салават-шәрифләре булса иде"-дип дога кылып башлый.

Килгән хаҗиларыбыз тәваф кылганда елый-елый догалар кылалар. Аллаһы Тәгаләдән җәннәтне сорыйлар. Мин дә тәваф кылам, тәваф кылганда шатлыгымнан күңелләрем тулып елыйм, Аллаһыдан дөнья һәм ахирәт бәхет-сәгадәтен сорыйм. Хаҗилар кара ташны үбәргә теләп әкрен генә аңа таба баралар. Ләкин анда барып ташны үбәр өчен бик күп көч кирәк. Чөнки халык шулкадәр күп, һәм аларның күбесе гомерләрендә беренче мәртәбә килгәнгә, ничек булса да шул ташны үбәселәре килгәнгә, берәм-берәм кара таш ягына таба ыргылалар. Артыма борылып карасам, минем белән килгән хаҗилардан бары тик биш-алты гына кеше калган. Минем дә кара ташны үбәсем килә дип, кара ташка таба юл алдым. Бик авыр булса да аның янына кадәр барып җитеп, ташны үбү насыйп булды.

Мин шулчак елый-елый:"Я,Раббым Аллаһ, менә мин Синең йортыңда. Я, Раббым Аллаһ, менә мин Синең әмереңне ишетеп Синең йортыңа аяк бастым һәм Синең йортыңны тәваф кылам. Я, Раббым Аллаһ, миңа ошбу үзем белән алып килгән хаҗиларның барысын да бергә тупларга ярдәм бир, миңа алар белән берлектә хаҗ гамәлләрен үтәргә ярдәм бир һәм барысын да исән - имин туган илебезгә алып кайтырга ярдәм ит",-дип бик күп догалар кылдым. Бәйтулаһта кылган догаларым һичшиксез кабул булуына ышанып дога кылдым.Аллаһы Тәгалә безгә: "Дога кылып миннән хаҗәтегезне сорагыз",- дип әйткән. Без мөселманнар барыбыз да Аллаһның үзеннән сорап дога кылырга тиешбез. **Һәр әйләнешнең ахырында, кара таш белән Йәмән почмагы арасында:** "Раббыбыз безнең! Бу дөньяда да һәм киләсе дөньяда да барлык хәсәнәтләреңне бир һәм Ут газабыннан сакла безне!"-дип дога кылына.

Тәваф кылып тәмамланганнан соң барыбыз да ике рәкәгать тәваф намазы укыдык. Беренче рәкәгатьтә"Фәтыйха" белән "Ихлас" сүрәләрен укыдык.

Пәйгамбәребез с.г.в.с. шулай эшләгән. Аңарга Аллаһы Тәгалә шулай кушкан. Без дә шул рәвешле укыдык. Ике рәкәгать намаздан соң зәм-зәм коесы янына барып туйганчы зәм-зәм суы эчтек. Аның махсус догасы бар, шул доганы кыйблага табан карап кылдык. Дога: "Әй,Раббым Аллаһ, миңа файдалы гыйлем, киң ризык һәм авыруларыма шифа бир",-дигән мәгънәдә. Зәм-зәм суын эчеп, догаларны кылганнан соң, Сафа тавына мендек.

Сафа тавына менгәндә, әс-Сафә һәм Әл-Мәрвә тауларына менгәндә Коръәннең шушы аяте укыла:

"Дөреслектә, әс-Сафә һәм әл-Мәрвә Аллаһының билгеләреннән булып тора. Кем дә кем Изге Йортка хаҗ яки гомрә кылырга ниятләгән булса, шул ике тауның арасын әйләнсен. Кем үзе теләп изгелекне сайласа, белеп торсын, Аллаһы Тәгалә һәр изге эшкә әҗер-савабын бирүче һәм бар нәрсәне дә Белүче," -дип укыла.

**Әс-Сафә һәм Әл-Мәрва тауларына күтәрелгәч, хаҗи, Кәгъбәтуллаһны карашы белән эзләп табып, шуңа таба борылып:**

"Аллаһы Тәгаләдән башка бүтән бернинди илаһи зат юк, Ул бер ялгызы. Аның бер нинди дә тиңдәше юк. Барлык хөкем фәкать Аның кодрәтендә генә. Барча мактау фәкать Аңа гына һәм Ул бар нәрсәгә дә кодрәтле! Аллаһы Тәгаләдән башка бүтән бернинди илаһи зат юк. Ул Үзенең биргән вәгъдәсендә торды, барлык кабиләләрне тар-мар итеп Үзенең колына ярдәм итте!"-дигән доганы укый.

Сафа тавы бәйтуллаһтан ерак түгел, аларның арасы бик якын-йөз метр тирәсе. Кайбер кешеләр тау дигәч Сафа белән Мәрвә тавын Тянь-Шань таулары шикеллерәк зур таулар дип уйлап, әл-Хәрәм мәчетеннән чыгып, Сафа, Мәрвә тауларын бик нык эзлиләр. Әйткәнемчә, ул таулар мәчетнең эчендә генә, гарәпчә укый белә торган кешеләр аны укып белә алалар. Аның исеме тактага язылып, бөтен кеше күрерлек итеп биек урынга эленеп куелган. Без Сафа тавына менеп Пәйгамбәребез йөргән урыннарда җиде мәртәбә:дүрт мәртәбә Сафадан Мәрвәгә бардык, өч мәртәбә кайттык. Җәмгысы җиде мәртәбә булды.

**Кунакта**

Тәлгать Таҗетдин хәзрәтләрен Мәккәдә бик күп кешеләр таный икән дигән фикергә килдем. Аның белән йөргәндә кая гына барма, кая гына кермә, хәзрәтне

барысы да таный, барысы да хөрмәт итә, барысы да үзенең ашына яисә кичке ашка кунакка чакыра. Без хәзрәт артыннан ияреп кенә йөрүчеләр. Хәзрәт безне үзе белән кунакка алып бара. Мул өстәлләр артында кунак булып утырганда Сочидагы мәшәкатьләр дә,аэропорттагы визасызлык аркасында килеп чыккан проблемалар да, мунчада кияр өчен ясалган резина башмаклар да- барысы да онытыла. Алдыбызда-мул ризык. Король Тәлгать хәзрәткә кунакны хөрмәт итеп йөртер өчен машинасын да,шоферын да биргән. Кая гына булмасын, машина белән барабыз, машина белән кайтабыз. Рәхәтлеккә тарыдык, әлхәмдулилләһ. Авырлыктан соң җиңеллек дигән, менә инде аның җиңеллеге.

Бер көнне без **Җ**иддә шәһәрендәге бер зур генералның өендә кунакта булдык. Ул кунакларга дип төрле-төрле ашлар,пылаулар пешерткән, табынның уртасына бик зур гына балыкны матур итеп бизәкләп чыгарып утырткан нар.

## Руза тоту

Тәмәттугъ хаҗы кылучыларның акчалары булмаса, Мәккәдә өч көн, туган илләренә кайткач җиде көн руза тоталар. Аллаһының расуле безгә хаҗның өч төрле икәнен аңлатып, өйрәтеп калдырган.

Хаҗ 3 төрле була: кыйран, тәмәттугъ һәм ифрад. Кыйран хаҗы барыннан да артыграк. Кыйран - ихрам баглый торган урыннарньң берсендә хаҗ, белән гомрәнең һәр икесен бергә ният кылып ихрам баглаудыр.

Кыйран хаҗын ният кылган кеше Мәккәи Мөкәррәмәгә баргач та гомрәсен кылыр да ихрамнан чыкмыйча шул ихрамы белән фарыз хаҗны да кылыр.

Тәмәттугъ хаҗы ифрадтан, ягъни ялгыз хаждан артыграк. Тәмәттугъ хаҗын ният кылган кеше микатларның берсендә гомрәне ният кылып ихрамын баглар да Мәккәи Мөкәррәмәгә баргач гомрәсен тәмам итеп чәч алдырганнан яки кыскартканнан соң Тәрвия көненә кадәр ихрамнан чыгып торыр. Тәрвия көнендә, яисә әүвәлрәк хаж, өчен Мәсҗид Хәрәмда гына ихрам баглар да ялгыз хаж, кебек хаж кылыр.

Ифрад, ягъни ялгыз хаж – фәкать хаҗны гына ният кылып хаж, кылудыр.

Кыйран һәм тәмәттугъ хаҗын ният кылып хаж, кылган кешеләргә хаҗларын кылып, чәчләрен алганнан соң корбан чалулары вәҗеп була. Әгәр корбан чала алмасалар, гает көненнән әүвәл өч көн, хаж, гамәлләреннән соң, өйгә кайткач

җиде көн, барысы ун көн ураза тоту тиеш була. Әгәр гает көненә кадәр өч көнне тота алмый калса, корбан чалу вәҗеп була.

Акчалары булган кешеләр корбан чалалар, руза тотмыйлар. Безнең кесә төбендә маяга бераз акча калган булса да корбан чалырга җитми иде. Шулай булгач, мин Мәккәдә чагымда өч көн буена илле градус эсселектә руза тоттым. Руза тоткан вакытта да мин хәзрәтләр белән йөрдем. Дөресен әйтим, алар кунак булып сыйланган вакытларда миңа сусаган хәлдә яннарында йөрү бик авыр булды. Аллаһының рәхим - шәфкате, ярдәме белән өч көн руза тотуым аркасында бер сарык бәясен - 85 доллар акчаны янга калдырдым. Әлхәмдулиллаһ, Мәккә шәһәре никадәр генә эссе булса да, руза тотуы бик авыр булмады, бары тик бераз сусатты гына. Аллаһының рәхмәте белән, рузаларымны тотуны тәмамладым. Хажда вакытта өч көн руза тотарга ниятләгән кешеләр барысы да олы хаҗ көннәренә кадәр уразаны тәмамларга тырышалар. Чөнки олы хаҗ, вакытында беренчедән руза тоту авыр. Ә иң мөһиме- Гарәфә көнендә хаҗ, кылучы мөселманнарга бөтенләй руза тотарга ярамый. Ул көнне хаҗилар ашап-эчеп, кунак булалар. Әгәр дә Гарәфә көнне руза тотсаң, әҗерле түгел, бәлкем гөнаһлы буласың. Ул көндә руза тоту Гарәфәдәге хаҗиларга хәрәм булып санала. Ә башка көннәрдә, мисал өчен, Минада тәрвия көннәрендә, руза тоту рөхсәт ителә. Ләкин олы хажны башлаганга кадәр уразаны тотып кую хәерле. Чөнки син ул көннәрдә бүлмәңдә ял итә аласың. Ә олы хаҗ, вакытында гел хәрәкәттә буласың. Ул көннәрдә хаҗилар бик нык арыйлар. Мин олы хаҗга кадәр ниятләгән рузаларымны тотып, өстемдәге бурычны үтәдем.

## Сигезенче зөлхиҗҗә

Мәккәгә хаҗ кылырга килгән хаҗилар сигезенче зөлхиҗҗә көнендә олы хаҗны кылырга тотыналар. Без дә гомрә хаҗын кылып, бер атна дәвамында булган әйберләребезне сатып, кирәк-яракларны алып, кунакка йөреп, рузалар тотканнан соң, олы хаҗны кылырга керештек. Хаҗиларның күбесен автобуслар Мәккәдән Минага илтергә тиешләр. Мәккәдән Мина үзәнлеге бик ерак түгел. Бәйтуллаһтан ун-унбиш минут эчендә тиз генә барып җитеп була булуын. **Җ**әяү барсаң, бер сәгать ярым тирәсе вакыт житә. Ләкин без Минага гомеребездә беренче тапкыр гына барганлыктан юлны белмибез. «Минага барам!» - дип

Аллаһыга тәвәккәлләп чыксаң юлын да табарсың Раббым ярдәме белән, әлбәттә. Юкка гына халык: «Тел Кытайга кадәр илтә» дими. Ләкин бит эш анда гына түгел, мәсьәләнең икенче ягы бар - анда баргач синең өчен әзерләнгән урынны каян табасың әле.

Мина ул - өч миллион кешене сыйдыра торган, Мәккәдән унбиш чакрым ераклыктагы бер узәнлек. Ул үзәнлекнең кырыйлары тау белән әйләндерелгән. Шунда бөтен дөньядан килгән мөселманнар сигезенче зөлхиҗҗә көнендә баралар.

Минада урнашканда ахшам намазы якынлашып килә иде инде. Барыбыз да ахшамга кадәр икендене кыскартып ике рәкәгать итеп үз вакытында укыдык. Аннан соң ахшам намазына кадәр палаткаларда бераз ял иттек. Ахшам намазы кергәч, Минада җыелган халык бергә җәмәгать булып намазларын укый алмыйлар. Һәр төркем үзләре палаткаларда җәмәгать булып намаз укыйлар.Без дә үз палаткаларыбызда намазларыбызны укыдык. Намаздан соң җитәкчеләр хаҗиларга вәгазьләр сөйлиләр. Бигрәк тә Төркиядән килгән имамнар үз халкына бик көчле итеп вәгазь сөйлиләр. Мин аларның вәгазь сөйләүләрен игътибар белән тыңладым. Аларның хәтта муеннарындагы кан тамырлары кысылып киткән кебек күренде.

**Тугызынчы зөлхиҗҗә Гарәфә көне**

Пәйгамбәребез с.г.в.с. үзенең хәдисендә «Хаж, ул – Гарәфә» - ди.

Ягъни хаҗга килүче кеше Гарәфәдә булмаса, ул кешенең хаҗы хаҗга саналмый дигәнне аңлата. Мәккәгә хаҗ гамәлен кылырга килүчеләр хаҗи дәрәҗәсенә ирешер өчен иң беренчедән ихрамга керергә тиеш булсалар; икенчедән, Гарәфә дигән урынга барып, шунда билгеле вакытта тору; өченчедән, Аллаһ йорты бәйтуллаһны Гарәфәдән соң тәваф кылудыр. Шуларны эшләгән кеше хаҗи дәрәҗәсенә ирешә. Әбу Хәнифә мәзһәбендә хаҗның өч шарты, ике әркәне бар.

Шартлары:

1.Билгеле вакыт;

2.Билгеле урын;

3.Ихрамга керү.

**Билгеле вакыт**. Намазның вакыты булган шикелле, олы хаҗның да билгеле вакыты бар. Әгәр вакыты кермичә укысаң, намазың кабул булмый. Шуның кебек хаҗның да вакыты бар.  Әгәр вакыты кермичә кылсаң, хаҗың да кабул булмый. Хаҗ  вакыты дигәндә ике нәрсә күз алдында тотыла. Беренчесе – Гарәфә вакыты, икенчесе – бәйтуллаһны тәваф кылу вакыты. Гарәфә көнне аңа барырга соңга калсаң, ул чагында хаҗсыз кайтып китәсең. Хаҗның бит намаз шикелле казасы юк. Әгәр кеше берәр сәбәбе булып намазын калдырса, аны каза кылып куя. Ә Гарәфәнең казасы юк. Бүген анда кеше күп, шуңа күрә иртәгә кешеләр таралгач барып казасын кылырмын дип әйтеп булмый.

**Икенче шарты-махсус урын**

Махсус урын дигәнднә, ике урынны күз алдына китерәбез. Аның беренчесе-Гарәфә. Гарәфә дөньяда, ягъни **Җ**ир йөзендә бер урында гына,андый урын башка беркайда да юк.Гарәфәнең чикләрен билгеләп һәм зур такталарга махсус билгеләр ясап куйганнар.

Икенче махсус урын-ул Хәрәм мәчете. Менә шунда барып тәваф кылу тиешле.Бу мөһим шарт булып тора.

**Өченче шарты-ихрамга керү**

Без намаз укырга дип намазга тәкъбир әйтеп керәбез. Намазга кергәннән соң безгә дөнья эшләрен башкарырга ярамый. Намаз укыганда тырнак та кисмибез, \ чәч тә алдырмыйбыз, ашамыйбыз да, эчмибез дә. Шулай ук, намазга кергән шикелле, хаҗ кылу вакыты житкәч, зөлхиҗҗәнең сигезенче көнендә без ихрам киемнәрен киеп, “Ләббәйкә Аллаһуммә хаҗ” дигән сүзне әйтеп ихрамга керәбез. Хаҗ гамәлләрен үтәргә ниятләп керәбез. Менә шул сәгатьтән без ихрамда булып саналабыз. Ул вакытта безгә кайбер хәләл булган эшләрне дә кылырга ярамый.

**Хаҗ әркәннәре**

Хаҗның ике әркәне бар.

Хаҗ әркәннәренең беренчесе-Гарәфәдә тору.

Икенчесе-тәваф кылу.

Кайбер кешеләр “Әркән” дигән сүзне аңламыйлар. Нәрсә соң ул әркән? Без сезнең белән иман әркәннәре, ислам әркәннәре, намаз әркәннәре хакында ишеткәнебез булса да, кайбер кешеләребез аңлап бетерә алмыйлар. Аңлату өчен

тормыштан, яшәештән мисаллар китерәм. Мәсәлән, әгәр кибеттән бер хаймә (палатка) сатып алсак, ул палатка эчендә яшәр өчен аны җыярга кирәк. Башта булачак палатканың кырыйларына чөйләр кагыла, аннары палатканың уртасына бер терәү, дүрт ягына дүрт терәү куеп күтәрәбез. Соңыннан аның җепләрен чөйләргә ныгытып беркетәбез. Терәүләре булмаса, палатканы күтәреп буламы? Әлбәттә, юк. Әгәр дә өйнең нигезе һәм диварлары булмаса, аның тәрәзәсе, идәне, түшәмнәре һәм түбәсе булу белән генә ул өй була аламы? Була алмый. Иң кирәге - нигез белән аның дивары. Әркән кешенең гәүдәсен тотып торучы баш белән арка сөяге шикелле. Әгәр кешенең башы һәм арка сөяге - умыртка баганасы булмаса, кеше яши алмый. Шуның кебек хаҗның да ике әркәне бар. Ансыз хаҗ, хаҗга саналмый. Беренчесе аның-Гарәфә көнне Гарәфәдә торудыр. Гарәфәдә бер минут кына торып өлгерсәң дә ул Гарәфәгә санала, син беренче әркәнен үтәгән буласың. Икенчесе аның икенче тәвафны –(фарыз) тиешле булган тәвафны кылудыр. Тәвафны без бәйтуллаһны җиде мәртәбә әйләнеп кылабыз. **Җ**иде мәртәбәнең дүртесе фарыз,өчесе вәҗеп булып санала. Шулай итеп, хаҗның өч шарты, ике әркәне булды.

Шартлары:беренчесе - билгеле вакыт; икенчесе-билгеле урын; өченчесе - ихрамга керү. Әркәннәре: беренчесе - Гарәфә тору; икенчесе - тәваф кылу.

Без тугызынчы зөлхиҗҗәдә иртән торып тәһарәт алып, иртәнге намазыбызны укыгач, үзебез белән алып килгән сумкаларыбызны алып палаткалардан чыктык. Безгә тагын автобусларга утырып Минадан Гарәфәгә барырга кирәк иде. Африка илләреннән килгән негрларның һәм Төркиядән килгән төрекләрнең күбесе пәйгамбәребез с.г.в.с. җәяү йөргән дип, Гарәфәгә җәяүләп баралар. Без дә “Негрлар Гарәфәгә җәяү китте”- дип алар артыннан җәяү барсак, барып җитәрбез, шәт, ләкин Гарәфәдәге палаткаларыбызны ничек табарбыз. Анда бит өч миллион кеше. Әгәр дә ялгыш кеше урынына керсәк, ул чагында без аларга золымлык кылган булабыз. Шуңа күрә без автобуслар белән барырга булдык.

**Без юлда**

Хаҗилар автобусларга кереп утырып намазларын укыгач,бераз капкалап алдылар да, креслоларга утырган килеш барысы да йокыга талдылар. Чөнки аларның йокылары туймаган, икенчедән, аларның бернинди дә эшләре юк. Төне

буе йокламаган шоферга гына бик тә уяу булып, хаҗиларны тиешле урынга илтеп җиткерү бурычы йөкләнгән. Ул хаҗиларны Минадан Гарәфәгә илтергә тиеш.

Минада Гарәфәгә 10-12 чакрым ара. Әгәр хаҗи аны җәяү үтәргә теләсә, ул иртәнге физзарядка кебек кенә булыр иде. анда ике сәгать ярым эчендә барып җитеп тә булыр иде. Ләкин без, беренчедән, юлны белмибез; икенчедән, үзебез белән алган әйберләребез дә шактый авыр; өченчедән, арабызда 80 яшьлек карт - карчыклар да бар. Әле җитмәсә,кайберләребез чирле. Шул сәбәпләр аркасында без җәяү бара алмыйбыз.

Аллаһының рәхмәте белән, Минадан Гарәфәгә киттек.

**Гарәфәдәге вәгазь**

Гарәфәдә имам булып укыткан кеше тагын бер сөннәт гамәлен үтәргә тиеш. Ул Гарәфәдәге вәгазьдер. Иң беренче Гарәфәнең шартлары, аның вәҗепләре һәм сөннәтләре белән танышып үтик.

**Гарәфәдәге шартлар**

Намазның шартлары булган шикелле, Гарәфәнең дә бердәнбер шарты бар. Ул - вакыт, ягъни билгеләнгән вакытта хаж,и Гарәфәдә торырга тиеш. Бу турыда алданрак сүз булган иде. Гарәфәдә тору өчен ният кирәк түгел, чөнки без ихрамга кергәндә ниятләгән идек инде. Әгәр бер кеше җенләнеп китсә, акылын югалтса, ягъни берәүнең акылын Аллаһ алыр булса , Гарәфәдә тору өчен акыл да шарт түгел. Үз акылында булмаса фарыз өстеннән төшә, димәк. Шулай ук һуштан язып, кайда торганыңны белмәсәң дә, Гарәфәгә килгән булсаң, өстеңнән Гарәфә гыйбадәте төшкән булып санала. Димәк, Гарәфәнең бер шарты - ул да булса вакытында килүдер.

**Гарәфәнең вәҗебе**

Әгәр хаҗи Гарәфәгә көндез килсә, ул кеше кояш батканчыга кадәр шунда торырга тиеш. Ул кояш батканчы кайтып китсә, ул чагында аңа хатасын төзәтер өчен бер сарык чалып Мәккә фәкыйрьләрен ашатырга кирәк булачак. Чөнки ул Гарәфәнең бердәнбер вәҗебен калдырган булып санала. Гарәфәгә көндез дә килә алмаса, ул чагында кич килә. Кичкырын килгән кешегә Гарәфәдә вәҗеп калмый. Чөнки ул вакытта вәҗепнең вакыты үткән була.

## Гарәфәнең сөннәтләре

Гарәфәнең сөннәтләре күп.

1.Гарәфәгә барганда госел алу.

2.Имамның ике хөтбә сөйләве.

3.Өйлә белән икендене бергә кыскартып уку.

4.Ашау-эчү. Хаҗи Гарәфәдә руза тотмый.

5.Гарәфәдә даими рәвештә тәһарәтле булу.

6.Имам кешегә якынрак булу.

7.Ихластан дога кылу.

8.Үзеңнең, әти-әниеңнең, мөселманнарның гөнаһлары ярлыкансын өчен дога кылу.

9.Тәлбияләр, зикер, тәсбихләр, тәхлилләр белән мәшгуль булу.

10.Пәйгамбәребез с.г.в.с.гә салаватлар әйтү

11.Кояш батканчыга кадәр Аллаһы Тәгаләдән хаҗәтләребезне үтәсен өчен дога кылу.

Хаҗ кылырга килгәннәр шартларын, вәҗеп сөннәтләрен тәртип белән белмәсәләр дә барысы да үтиләр, әлхәмдулилләһ.

Гарәфәдә бик арылган булса да Аллаһы Тәгаләгә хәмде сәнәләр пәйгамбәребез с.г.в.гә салават сәламнәр әйтеп, хаҗга килгән халыкка сәламнәр әйтеп вәгаземне башлап җибәрдем.

## Мөздәлифәгә кайтыр чак.

Хаҗилар Гарәфәдә кояш батканчыга кадәр торалар. Әгәр берәү кояш баер алдыннан Мөздәлифәгә кайтып китсә, ул чагында хаҗи вәҗеп гамәлен үтәмәгән булып санала. Ул аның өчен бер сарык чалып Мәккәдәге ярлыларга ашатырга тиеш була. Гарәфәдә без кояш баеганчы тордык. Без олы җитәкчебезнең әмерен көтәбез.Менә кояш батты. Хаҗилар Гарәфәдән кузгалып, Мөздәлифәгә таба агыла башлады. Бу Аллаһының әмере. Аллаһы Тәгалә Коръәндә: “Соңыннан башка кешеләр төркем - төркем булып төшкән җирдән (Гарәфә тавыннан) сез дә төшегез. Аллаһыдан ярлыкау сорагыз. Шөбһәсез ки, Аллаһ һәрвакыт ярлыкаучы, кичерүчедер”-ди. (Бәкара,199).

Аллаһы Тәгалә дәвам итеп:

“Хаҗ гыйбадәтләрегезне тәмамлалач, ата-аналарыгызны искә алган шикелле, алардан да ныграк Аллаһыны зиһенегездә тотыгыз”,-ди. (Бәкара, 200)

Бу аятьтән без Раббыбызны әти-әниләребездән дә артык искә алырга тиеш икәнлегебезне аңлыйбыз. Аллаһы Тәгаләнең әмерләрен көчебез җиткәнчә үтәргә тырышабыз. Менә инде без Гарәфә тавыннан Мөздәлифәгә таба барырга әзербез.

**Гарәфәдән мөздәлифәгә табан**

Ул вакытта юллар бушаган иде инде. Шуңа күрә без ул араны бик тиз үттек. Менә, әлһәмдүлилләһ, тагын җиңеллек килде! Барып җиткәннән соң ахшам намазы белән ястү намазын бергә укып, иртәнге намазга кадәр ятып йокладык. Мөздәлифәдә без палаткаларда кунмадык. Кемдер автобуста, кемдер җиргә ятып ял итте.

Минага баргач ыргытыр өчен җитмеш таш жыела. Ул ташлар чиядән кечкенә, борчактан зуррак булса хәерле, ләкин чия шикелле булса да зыян итми.

**Сорау:**Ни өчен җитмеш таш соң?

**Җавап:**Минага баргач беренче көнне җиде таш, икенче көнне өч урында җидешәр таш, өченче көнне җидешәр таш, әгәр калырга булса дүртенче көнне дә җидешәр таш атыла. Барысы җитмеш таш була**.**

Мөздәлифәдә иртәнге намаз сөннәте белән укыла. Намаздан соң дога кылына. Мөздәлифәдә менә шушы гамәл-гыйбадәтләрне кылганнан соң Минага кителә.

**Сорау:**Минага иртәрәк китәргә ярыймы?

**Җавап:**Хатыннарга,хәле авыр булган чирлеләргә төннең яртысыннан соң китү рөхсәт ителә. Без Мөздәлифәдә кунып иртәнге намазны укыганнан соң Минага киттек. Аллаһы Тәгалә кабуллардан әйләсен.

## Мәккәдән Мәдинәгә

Хаҗ гамәлен кылырга барган хаҗилар Мәккәдәге изге гамәлләрне үтәп бетергәннән соң пәйгамбәребез с.г..в.с.һиҗрәт кылган, ягъни күчеп китеп яшәгән Мәдинә шәһәренә барып андагы мәчетне зиярәт итәләр.

Мәдинә шәһәрендә хаҗилар Мөхәммәд с.г.в.с. мәчетенә керәләр, алар анда намазлар укыйлар. Анда елның теләсә кайсы аенда да барырга ярый.

**Җ**әбир бин Абдулла әйтүенчә, Аллаһыньң илчесе с.г.в.с. әйткән:

«Минем мәчеттә укылган намаз бүтән мәчеттә укылган мең намаздан өстенрәк, Әл-Хәрәм мәчетеннән кала. Ә әл-Хәрәм мәчетендә укылган бер намаз йөз мең намаз савабына ия». (Бу хәдис Әхмәд һәм Мин Маҗа тарафыннан тапшырыла).

Мәдинәгә килеп кергәч, хаҗига ән-Нәбәви мәчетенә бару тиешле, анда кергәндә түбәндәге дога укыла:

**«Аллаһы Тәгалә исеме белән! Пәйгамберебезгә Аллаһының рәхмәте! Шәйтан золымыннан Аллаһы Тәгаләгә сыгынамын, Аллаһы Тәгаләдән ярдәм сорыймын. И Раббым, рәхмәтеңне ирештер!»**

Ән-Нәбәви мәчетенә кергәндә укый торган аерым дога юк. Мәчет эчендә хаҗ кылучы ике рәкәгать намаз укый. Ә инде әр- Рауда әш-Шәрифәгә кергәндә укылса, тагын да хәерлерәк. Бу турыда хәдистә болай диелә:

**«Минем манарам белән өем арасында җәннәтнең бер бакчасы урнашкан».**

Намаздан соң ирләр пәйгамбәребезнең с.г.в.с. һәм Әбу Бәкер белән Гомәр р.г.нең каберләренә юнәләләр. Пәйгамбәр с.г.в.с.нең каберенә барып җиткәндә түбәндәге дога укыла:

«**Әс-сәләму гәләйкә я расүлү-л-лаһи уә рахмәтү- л-лаһи уә бәракәтүһү! Әс-сәләмү гәләйкә я нәбийя- л-лаһи! Әс-сәләмү гәләйкә я хира та-л-лаһи мин халкиһи! Әс-сәләмү гәләйкә я сәйидә-л-мурсәлинә уә имама-л-муттакыйнә!**

**Әшһәдү әннәкә кад бәлләгътә-р-рисаләтә, уә әддәйтә-л-әмәнә, уә нәсәхтә-л-уммә уә щәхәттә фи- л-ләһи ханка щиһадиһи!».**

«Тынычлык сиңа, Аллаһының Илчесе, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте вә шәфкате ирешсен! Тынычлык сиңа, Аллаһының Илчесе! Тынычлык сиңа, Аллаһы

Тәгаләнең яраткан бәндәсе! Тынычлык сиңа, пәйгамбәрләрнең олысы һәм иманлыларның имамы!

Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен синең көрәшүеңне, кешеләргә Аллаһының әмерен җиткергәнеңне, аларга ихлас киңәшләреңне дәлиллим!».

Аннан соң хаҗи Мөхәммәд с.г.в.гә дога кыла. Соңыннан Әбу Бәкер р.г.нең кабере янына туктала, сәлам бирә: «Әссәләму галәйкум, йә Әбу Бәкер». «Тынычлык сиңа, Әбу Бәкер».

Аннан Гомәр р.г. каберенә тукталып, шул ук сүзләрне кабатлый: «Әссәләму гәләйкум, йә Гомәр». «Тынычлык сиңа, Гомәр».

Хатын-кызлар кабер өстенә керми, чөнки аларга рөхсәт ителми. Ә эн-Нәбәви мәчетенә керергә ярый.

Ән-Нәбәви мәчетенә керүчеләргә ешрак Аллаһы Тәгаләгә зикер әйтергә тиешле, намаз укырга, Коръән укырга, бигрәк тә «Әр-Рауда әш - Шәрифә»дә вакытта, чөнки мондый бүтән мөмкинчелекнең булмавы мөмкин: без әҗәлебезнең җиткәнен белә алмыйбыз. Шуны әйтергә кирәк, бу гамәлләр фарыз түгел. Мәчеткә кергәч, мәчет диварларына тотынырга, үбәргә, Мөхәммәд с.г.в.с.гә ялварырга, үтенергә ярамый, чөнки бу шәригатьне һәм әхлакны бозу була. Бары тик күнелеңдә булган нәрсәләрне Аллаһы Тәгаләдән генә сорарга кирәк: «И Раббым! Пәйгамбәребезне безнең өчен яклаучылардан кыл!»

Пәйгамбәрнең кабере янында озак тормыйча, тыныч кына, сөйләшмичә, ялвармыйча чыгарга киңәш ителә.

Аллаһ илчесенең шәһәрен күрергә килүченең яшәгән урынында таһәрәтләнеп, Куба мәчетенә килүе хәерле, анда ике рәкәгать намаз укыган кешегә гомрә савабы була. Пәйгамбәребез с.г.в.с.:

«Үз өендә тәһарәт алып, Куба мәчетенә барып, анда намаз укыган кешегә гомрә үтәгәндәге кебек савап булыр» - дип әйтә. (Хәдисне Әхмәд һ.6. тапшыра)

Ибн Гомәр р.г.: «Аллаһының илчесе, с.г.в.с., Куба мәчетенә ат өстендә яки җәяү килеп, 2 рәкәгать намаз укый торган иде» - диде. Икенче бер хәдискә караганда, ул анда һәр шимбә бара торган булган. Хаҗиларның әл-Бакыйгъ һәм дин өчен вафат булган шәһиләрнең, бигрәк тә Хәмзә каберенә баруы мактала. Пәйгамбәребез дога укыган кебек, хаҗилар да аларга дога укырга тиеш:

**«Әс-сәләму галәйкүм әхлә-д-дияри мин әл- муэмининә үә-л-муслиминә, үә иннә иншәә-л-Лаһу бикүм ләхыйкун, нәсьәлу-л-Лаһа ләнә үә ләкүм әл-гафия!».**

**«Тынычлык сезгә, мөэмин мөселманнар. Тәхкыйк, Аллаһ боерса, без сезгә иярербез. Без Аллаһыдан сезнең өчен дә, үзебез өчен дә бәрәкәт сорыйбыз!»** (Хәдисне Мөслим тапшыра).

Ягъни:

**«Әс-сәләмү галәйкүм, я әхлә-л-кубур, ягфиру-л- лаһу ләнә үә ләкүм. Әнтүм сәләфүнә үә нәхнү би-л- әсәри!».**

**«Тынычлык сезгә, кабер әһелләре! Сезне дә, безне дә Аллаһ гафу итсен! Монда сезнең арттан без дә киләчәкбез!»**

Аллаһ илчесенең шәһәреннән чыгып китәр алдыннан, хаҗи кеше әл-Мәсҗид ән-Нәбәви мәчетендә Аллаһыга ялварып, ике рәкәгать намаз укыса, аннан соң изге кабер янына килеп, башта Аллаһы Тәгаләнең илчесенә, аннан Әбу Бәкер һәм Гомәргә р .г.сәлам бирсә хәерлерәк. Аннан ошбу дога укылыр:

«**Аллаһүммә лә тәҗгаль һәзә әхира-л-гәхди би- харами расулика үә яссирли-л-гәүдәтә илә-д-дия- ри-л-мукаддәсә, үә иля-л-хәрамәйни әш-шәрифәй- ни мәрратән үә мәрратән. Үә дҗгәләһә сәбилән сәхләтән бимәнникә үә фәдликә, үә-рзук-нә л'гафиятә фи-д-дини үә-д-унья үә-л-әхирати, үә руддәнә сәлимәнә гәнимикә илә әүтани-нә әмининә бирахмәтикә я әрхамә-р-рахиминә.**

**Үә салла-л-ләһу галә нәбийинә Мухәммәдин үә галә әлиһи үә әсәхбиһи әҗмәгин, үәл хәмдү ли-л- ләһи рабби-л-галәмин».**

«Раббым! Шушы йортыңа тагын килергә насыйп ит! Шушы изге җирләреңә кабат кайтуны җиңеләйт! Шул кайтуларны үзеңнең рәхмәтең вә мәрхәмәтең илә җиңеләйт! Динебезгә, фани һәм бакый дөньяда, тынычлык насыйп ит!

И Раббым, безне өйләребезгә исән-имин, уңышлы рәвештә кайтарсаң иде, дошманнардан сакласаң иде! Синең рәхмәтең үә мәрхәмәтең киң! Мөхәммәд пәйгамбәребезгә, аның рухына һәм сәхабәләренә Аллаһ мәрхәмәтен ирештерсә иде. Галәмнәр илаһысы Аллаһыга мактау!»

***

Үз гомерен Ислам диненә хезмәт итүгә багышларга ниятләгән Ишмөхәммәт, хаҗ кылгач, сигез ел Каһирәдә яши һәм мөселман уку йортлары арасында иң күренеклесе булган Әл-Әзһәр мәдрәсәсендә укый. (Әл-Әзһәр мәдрәсәсе 1961 елда университет дип игълан ителде.)

Әл-Әзһәр мөселман руханилары, шәригать нигезендә эш итүче казыйлар, мәдрәсә мөгаллимнәре әзерләгән. Әлеге мәдрәсәдә гыйлем алган кешенең абруе дин тотучылар арасында ифрат зур була.

Ишмөхәммәт хаҗи мәдрәсәдә укыганда бик өлгер, җитез акыл йөртүче фикер иясе һәм Коръәнне үзенчә матур итеп көйләп укучы буларак шөһрәт казана.

Шәкерт чагында Ишмөхәммәт күп вакытын китап күчереп язуга багышлый. Аның каллиграфиясе бик матур булганлыктан, ул күчергән китапларга сорау зур була. Ул күп акыл ияләренең, тарихчыларның хезмәтләре белән таныша, аларны өйрәнә. Гарәпчә, фарсыча һәм төрекчә иркен сөйләшә башлый.

Ишмөхәммәт хаҗи туган якларына үзе күчереп язган, аныңчы сирәк очраган “Әл-миркате шәрхел-мишкят” китабын алып кайта. Алты кисәктән торган әлеге китапны мөфти Шаһингәрәй улы Сәлимгәрәй Тәвкилев сатып ала һәм файдаланыр өчен Килем авылы мәдрәсәсенә бирә.

1897 елның 12 елның маенда булган янгында әлеге китап янып юкка чыга.

Ишмөхәммәт хаҗи үзе кулланган “Фәтавый” китабы Уфа Диния нәзарәтендә сакланган. Әлеге китапның бер битенә, Ишмөхәммәтнең үз кулы белән: ”1823 елның 13 гыйнварендә казага калган намазларымны янәдән каза кылырга башладым, мин фәкыйрь хаҗи Мөхәммәд, гәрчә сәфәр йөргәндә үтәгән булсам да,”-дип язылган.

Ишмөхәммәт Заитовның нәсел дәвамчысы Равил Шаһгали улы Ишмөхәммәтовтва тышына: “Шәех Мөхәммәд Трабзони Мәдәнинең- Әл-Итхәфәтүс - Саниә фии - Әхәдис әл - Кудсиә (Изге Хәдисләр) китабын тәрҗемә кылып күчердем мин,хаҗи Мөхәммәд”, - дип язылган, еллар үтү белән инде искереп, таушалып беткән,күп урыннарда язулары да җуелган кульязма китап саклана иде.1978 елның июлендә әлеге кульязма китапның укырга мөмкин булган бер өлеше безнең тарафтан күчерелеп алынды. Ишмөхәммәт хаҗи гарәпчәдән

тәрҗемә иткән Изге хәдисләр бүгенге әдәби тел таләпләренә яраклаштырылып тәкъдим ителә. Аларда, инде гасырлар үтсәдә, Ишмөхәммәтнең кул җылысы тоела,күз нурлары чагыла кебек.

**1-Аллаһы Тәгалә боера:**

“Миңа итагатьлек белән, Мине зикер итегез, Мин сезне Үземнең гафу итүем белән зикер итәрмен. Кем Мине итагать иткән хәлдә искә төшерсә, Мин аны, әлбәттә, Үземнең гафу итүем белән искә алырмын. Әгәр кем Мине итагатьсезлек иткән хәлдә искә төшерсә, Мин аны, әлбәттә, Үземнең ачу төшүем белән искә алырмын. Йә,Адәм баласы!

Көн башында дүрт ракәгать намаз үтәргә ялкауланма, Мин синең белән көннең ахырына кадәр булырмын. Үлемнең хаклыгына ышанып шат булуына гаҗәпләнәм Мин. Хисап булуына ышанып та, мал җыючыга гаҗәпләнәм Мин. Кабергә төшкәнен белеп тә көлеп йөрүчегә гаҗәпләнәм Мин. Әхирәт көненә ышанып та ял итүчегә гаҗәпләнәм Мин. Бу дөньяның бетүенә ышанып та кайгысыз яшәүчегә гаҗәпләнәм Мин. Гыйлеме телендә булып та йөрәге наданлыкта булучыга гаҗәпләнәм Мин. Су белән юынып та пычрак калучыга гаҗәпләнәм Мин. Кешенең гаепләре белән шөгыльләнеп үз гаепләрен белмәүчегә гаҗәпләнәм Мин. Аллаһ аның эшләрен белә торып гөнаһ кылучыга гаҗәпләнәм Мин. Үлгән вакытта үзе генә, күмелгәч каберенә үзе генә, гамәлләр өчен җавап биргәндә ялгыз үзе генә булуын белеп тә, кешеләргә бәйле булуына гаҗәпләнәм Мин. Дөреслектә Миннән башка Тәңре юк,һәм Мөхәммәд минем колым һәм илчем”.

**2-Аллаһы Тәгалә боера:**

“Миннән башка Илаһ һәм тиңдәш юк, ялгыз Үзем генә, Мөхәммәд Минем илчем һәм колым булуына, Мин Үзем Үземә шәһит булып торам.Һәр кем минем тәкъдиремә риза булмаса, бәла-казаларга сабыр итмәсә, нигъмәтләремә шөкер итмәсә, Мин биргән нәрсәләргә канәгать булмаса, Миннән башка Илаһ эзләп карасын. Кем иртән торып бу дөньяга ачу тотса, Миңа ачу тоткан кебек булыр. Кем бирелгән насыбына зарланса, Миңа зарланган була. Кем байга байлыгы өчен генә ярарга тырышса, ул иманның өчтән бер өлешен югалта. Кем мәет өстендә үкси - үкси еласа, кулына сөңге, ук алып Раббысы белән сугышканга тиңдер. Кем

кабер өстендәге үләнне өзсә, Минем Кәгъбәне үз кулы белән җимергән кебек була. Кем ашаган нәрсәләренә ихтибар итмәсә (хәләл - харамлыгын), Аллаһы Тәгалә аны кайсы җәһәннәм ишегеннән кертүне кайгыртмас. Кем көннән көн тәкъвалеген һәм изгелеген арттырмаса, ул зыян күрү, зыян күрүдән үлем хәерлерәк. Кем гыйлемен гамәл белән бәйләсә, Аллаһы Тәгалә аңа белмәгән нәрсәләрдә белем бирер, ә кемнең хыялы һәм теләге күп булса, аның гамәле ихлассыз булыр".

**3-Алллаһы Тәгалә боера:**

"Йә, Адәм баласы! Бел, канәгать булган, бай булыр. Хөсидне калдырган ял итәр. Кем харамны калдырса динен һәм иманын тазартыр. Кем гайбәт сөйләмәсә кешелек мәхәббәтенә ирешер һәм яхшылыкларын арттырыр. Кем кешеләрдән аерылса, алардан сакланыр. Күп сөйләмәгән, акылында камилдер. Әзгә риза булган, Аллаһы Тәгаләдә булганына өметләнә ала.

Йә, Адәм баласы! Син белгәнең белән гамәл кылмыйча, ничек син белмәгәнеңә гыйлем таләп итәсең? Гомереңне бу дөнья өчен әрәм итеп, җәннәткә керергә тырышмыйсың, иртәгә үләчәгеңне белмәгән кебек һәм байлыгыңны мәңге яшәгән кебек җыясың. Аллаһы Тәгалә бу дөньяга боерды: "Сине теләгәннәргә үзеңне харам кыл, синнән заһиденә ачып, Теләүчеләре белән кулланып, заһидларга хезмәт ит!".

**4-Аллаһы Тәгалә боера:**

"Йә, Минем колларым! Мин алтын белән көмешне сезгә ризыкларны һәм киемнәрне сатып алыр өчен яраттым. Аның өчен Минем исемнәремне мактап бөекләгез һәм андый нигъмәтләргә шөкер кылыгыз. Аларны Миңа буйсынуда һәм хезмәт итүдә кулланыгыз. Сезнең җәннәт юлыгызда ярдәм итү өчен алар сәбәбче булсын һәм сезне җәһәннәм утыннан саклауда. Ләкин сез дөньяга алданып Миңа каршы барырга ярдәмче итеп аларны аласыз һәм Миннән башка аларга гыйбадәт кылып бөтенесеннән өстен куясыз. Минем китабымны аяк астына салып, өйләрегезне бөек салдыгыз һәм матурладыгыз, ләкин Минем өйләремне - мәчетләрне түбән кылып ямьсезләдегез. Шуның өчен сезгә яхшылык та, намус та юк. Йә, Минем колларым! Дөнья һәм аның байлыклары җыештырылган кабер кебек ,тышы матур итеп күренә, ләкин эчтән куркынычтыр. Сез кешеләрне, алар

сезне охшатсын, сөйсен өчен, тәмле сүз һәм матур эш белән белән алдарга тырышасыз. Минем каршыма каты йөрәкләр һәм ямьсез эшләр белән килеп басасыз. Йә, Адәм баласы! Сезнең начар гамәлегез белән изгелеккә өндәвегез өй түбәсендә утсыз фонарь кебек,бер файда да китермәс. Йә, Адәм баласы! Гамәлеңне Минем ризалыгым өчен эшлә. Йә, Адәм баласы! Минем ризалыгым өчен эшләнмәгән гамәлеңне кабул итмим. Миннән динеңә файда китермәгән нәрсәне сорама һәм Мин сиңа сораучыларның иң хәерле теләкләрен бирдем".

**5- Аллаһы Тәгалә боера:**

"Йә, Адәм баласы! Бел, Мин сезне шаярып та бушка яратмадым һәм Мин сез кылган эшләрегездән гафил түгел. Дөреслектә, сез Миндә булган нигъмәтләрне, минем ризалыгымны табуда сезгә охшамаган нәрсәләргә сабыр итүегез белән генә ирешерсез. Минем кушканнарыма сабыр итү, гөнаһ эшләргә сабыр итүдән җиңел. Бу дөньяда бозыклыкларны ташлау, ахирәт газабыннан күпкә җиңел. Йә, Адәм баласы! Һәр берегез адашкандыр, Мин һидаят юлына бастырганнардан башка. Һәр берегез чирледер, Мин шифа биргәннәрдән башка. Һәр берегез фәкыйрьдер, Мин байлык биргәннәрдән башка. Һәр берегез һәлакәттә, Мин саклаганнардан башка.Һәм һәр берегез гөнаһ кылучы, Мин тыйганнардан башка. Аллаһы Тәгаләгә гөнаһларыгыздан тәүбә итегез. Ул сезгә Рәхмәтен бирер.Аллаһы Тәгаләдән оялыгыз, дөреслектә Ул бөтен серләрегезне белүче".

**6- Аллаһы Тәгалә боера:**

"Йә, Адәм баласы! Мин яратканнардан берсен дә каргама, чөнки каргыш сиңа үзеңә кире кайтыр. Йә, Адәм баласы! Күкләр һавада бер нинди таянычсыз торадыр, аны минем исемнәрдән берсе генә тотадыр. Ләкин сезнең йөрәгегезне тулы китабым да вәгазьли алмый. Йә, Адәм баласы! Белегез, ташны су йомшарта алмаган кебек. сезнең каты йөрәкләрегезгә дә вәгазьләр файда бирмәс. Йә, Адәм баласы! Син төче су эчеп Мине мактамыйсың һәм тәмле ризык ашап Миңа шөкер кылмыйсың. Сиңа уңайсызлык китергән нәрсә, җиңеллек белән синнән чыгадыр һәм син аңа бер нинди дә игътибар бирмисең. Син хәрәмнән тыелмыйсың, гөнаһ кәсеб итәсең һәм уттан курыкмыйсың. Рәхмәтле Аллаһ Тәгаләнең ачуыннан курыкмыйсың. Йә, Адәм баласы! Башта сез Раббыгызның коллыгына шәһадәт

биреп, ничек соңрак Аңа каршы киләсез? Үлем хак икәнлеген белеп ни өчен Аны күрә алмыйсыз? Җиңел уйлап сез белмәгән нәрсәләрне сөйлисез, ләкин Аллаһ хозурында ул зур гөнаһ?”

**7- Аллаһы Тәгалә боера:**

“Йә, кешеләр! Бу дөнья –гыйбарәт йорты, ягъни зур ышанычлар белән торган урын түгел .Ул фани дөньяны нык хөрмәт итмәгез, әлбәттә, аның нигъмәтләре тиз бетүче һәм гомере киселеп калучы. Сезгә үлем килгәнче аңарга изге гамәлләр белән әзерләнегез. Кая соң сезнең үлгән этиләрегез һәм балаларыгыз, бу сезгә гыйбрәт һәм дәрес түгел мени? Пәйгамбәребез (Аллаһ Тәгаләнең аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) әйтте: ”Мин җәннәт капкасы янында басып торганда, анда мескеннәр, ятимнәр һәм ярлыларның керүен күрдем.Ләкин бай һәм дәрәҗәле кешеләр көтеп тора иделәр”.Бу дөнья җәннәттә урыннары булмаганнарның йорты, байлыклары җәннәт нигъмәтләреннән өлеш булмаганнарга. Аны ни өчен җыйганын аңламаган кеше җыяр. Шуңарга акылы булмаган кеше шатланыр. Аны бер нәрсәдә ышанычы булмаганы теләр. Бер нәрсә белмәгәне аның шәһвәтләренә алданыр. Кем үтәүче нигъмәтләрне, кыска гомерне һәм фани шәхвәтләрне сөйсә, үзенә генә золымлык китерә, Раббысына гөнаһ кыла, ахирәтен оныта һәм бу дөньяга алдана. Йә, Адәм баласы! Күпме генә кешене Аллаһ бөек дәрәҗә һәм урын белән бүләкләде, әмма мәңгелек дөньясында аларга зур җәза гына булыр. Күпме кемнең турында яхшы сүзләр сөйлиләр, дөреслектә алар үз-үзләрен газапка дучар итәләр,алар кеше сүзенә алданып үзләрен изге һәм яхшылардан саныйлар, ләкин раббылары каршында алар гөнаһлылар. Моның белән алар үзләрен генә һәлак итәләр. Һәм күпме һәлак булучыларны мин коткардым, күп кешеләр үзләренең гөнаһлары өчен һәлак булырлар иде, әмма Аллаһы Тәгалә аларның җитешсезлекләрен яшерде. Күпме бу дөньяның җәзасызлыгына алданып гөнаһка баталар. Дөреслектә, кем бу дөньяда гөнаһ эшләүне туктатмаса, мәңгелек аның өчен ахирәттә куркыныч газапка ирешер. Йә, Адәм баласы! Минем өчен чәчегез. Мин сезгә бирермен. Минем өчен эшләгез, рәхмәтемә ирешерсез һәм Минем өчен файда табыгыз. Мин сезгә табыш бирермен. Миндә бер колак та ишетмәгән, бер күз дә күрмәгән, бер йөрәк тә сизмәгән җәннәт нигъмәтләре бар. Аларның иң яхшысы Минем колларым өчен-

Мине күрү, ул кеше күргән, ишеткән һәм сизгәннең берсенә дә һич охшамагандыр. Ул бәхеткә Мөхәммәд Пәйгамбәребездән (Аллаһның рәхмәте һәм бәрәкәте булсын аңа) башка бер адәм баласы да ирешмәде. Миндә бер кайчанда бетми һәм кимеми торган нәрсәләр бар һәм Минем хәзинәләрем һич кайчан бушамас. Һәм Миңа гафу сораучы гөнаһлы колларымның, Мин тәүбәләрен кабул итүче, Миңа тәсбих, зикер, шөкер кылучыларга Мин рәхмәтемне һәм бердә бетми торган җәннәт нигъмәтләрен бирүче. Шуның өчен хәдистә әйтелә: "Мин колыма ул күз алдына китерә алмаган кадәр якынмын, әгәр мине искә төшерсә, Мин аның янында."

**8- Аллаһы Тәгалә боера:**

"Йә, Адәм баласы! Үзегезнең теләкләрегезгә карата Миңа итагать итегез, сезнең сабырлыгыгыз Минем җәһәннәм утына җитмәс. Сезгә кирәкле кадәр бу дөньяда хезмәт итегез, ул сезнең гамәл йортыгыз. Һәм сезнең әҗәлегезнең ераклыгы, ризыкның барлыгы, гөнаһларыгызның яшерен булуы белән алданмагыз. Дөреслектә бөтен нәрсә һәлактә, хөкем итүче Аллаһы Тәгаләдән башка һәм Аңарга кайтарылачакбыз. Йә,Адәм баласы! Әгәр сез җәһәннәм утыннан фәкыйрьлектән кебек саклансагыз, Мин сезне аңардан саклармын һәм сезне сез көтмәгән җирдән ризыкландырырмын. Әгәр сез җәннәтне бу дөньяны кебек теләсәгез, Мин сезгә ике дөнья бәхетен бирермен. Әгәр Мине бер - берегезне кебек искә төшерсәгез, сезне көне - төне фәрештәләр сәламнәр. Әгәр сез Минем изге мескен колларыма дәрәҗәле һәм башка кешеләргә кебек игымлы булсагыз, Мин сезгә илчеләр хөрмәтен бирермен. Ләкин сез бу дөньяны яратуыгыз белән үтерәсез,ә аның ахыры якын".

**9- Аллаһы Тәгалә боера:**

"Йә, Адәм баласы! Синең тәнең ит һәм каннан тора,шуңа күрә аларга хәләл ризык бул. Әгәр үзеңнең гамәлеңне төзәтсәң, итең һәм каның җәннәткә ярарлык булыр. **Җ**әннәткә хәрәм һәм шикле булган нәрсәләрне үчләүчеләр кермәсләр. Кешеләргә яктыртыр өчен генә үзен бетергән шәмгә охшама. Йөрәгеңне үтергән, тәнеңне бозып һәм яндырып җәннәткә яраксыз итеп эшләгән бу дөнья сөюне үзеңнән чыгар. Чөнки Мин бер кайчан да бер йөрәктә Мине сөю һәм дөнья сөю мәхәббәтен бергә җыймам. Үзеңне ризык эзләү белән этләмә. Дөреслектә дөнья

ризыгы һәр берсенә бүленгән, аны эзләгән мәхрүм калган, ә аның нигъмәтләре озакка сузылмаган. Әҗәлнең тәкъдире бардыр, Аллаһы Тәгаләнең сүзләренең хаклыгы мәгълүмдер. Хикмәтнең иң хәерлесе Аллаһы Тәгаләдән курку. Байлыкның иң хәерлесе канәгать булу. Минем биргәннәремнең иң хәерлесе гафу итүем. Сүзләрнең иң начары ялган сөйләү. Эшләрегезнең иң начары яла ябу.Һәм Мин үземнең колларыма гаделсез түгелмен".

**10- Аллаһы Тәгалә боера:**

"Йә, Адәм баласы! Сабыр һәм тыйнак булсаң, дәрәҗәңне күтәрермен. Миңа шөкер итсәң, арттырырмын. Гөнаһларыңнан үкенсәң, гафу итәрмен. Туганнарың белән аралашсаң, гомереңне озынайтырмын. Күп сүзле булмыйча рәхәтлек сорасаң, бирермен. Бел, сәламәтлек ялгызлыкта, ихласлык саф күңелдә, изгелек тәүбәдә, гыйбадәт гыйлемдә, байлык булганына ризалыкта. Йә, Адәм баласы! Ничек күп йоклап Мине йөрәгең белән танырга телисең? Ничек фәкыйрьлектән куркып, тәкъвалыкны телисең? Күп гөнаһларың белән ничек Аллаһ ризалыгын телисең? Ничек син саран булып, хөрмәт тели аласың? Ничек син шөһрәт, данны һәм мактауны сөеп, хикмәтне тели аласың? Аз гыйлемең белән ничек бәхетне тели аласың?"

**11- Аллаһы Тәгалә боера:**

"Йә, Адәм баласы! Үлем сереңне ачар, кыямәт көне хәбәреңне сөйләр һәм гамәл китабың эшеңне күрсәтер. Шуңа күрә әгәр бер кечкенә гөнаһ эшләсәң аның зур булмаганлыгына карама, ләкин Кем каршында гөнаһлы булуыңны аңла. Һәм әгәр бераз ризык белән ризыклансаң, син аның азлыгына зарланма, Кем аны башкасына бирмичә сиңа биргәненә кара. Син гөнаһларыңны жыйма,әлбәттә белә алмыйсың кайсысы белән Минем ачуыма тиярсең.Һәм аның өчен ризыгымны кисәрмен һәм күк ишекләрен бикләп синең догаңны кабул итмәм. Син Минем мәкеремнән һәм ачуымнан имин калдым дип уйлама, Минем мәкерем караңгы төндә таштагы кырмыскадан да яшеренрәк. Йә, Адәм баласы! Сез Миңа гөнаһ кылганнан соң, Минем ачуымны искә төшереп, гөнаһтан тукталдыгызмы? Байлыгыгыздан мохтаҗларга өлеш чыгардыгызмы? Сезгә начарлык китергәнгә яхшылык теләдегезме? Сезнең белән мөгамәләне өзгәннәре белән аралаштыгызмы? Сезгә хыянәт итүченең вәгъдәсендә тордыгызмы?

Балаларыгызга яхшы мөселман тәрбиясе бирдегезме? Күршеләрегез хаҗәтен үтәп ризалыкларын алдыгызмы? Галимнәрдән үзегез белмәгән дини мәсьәләләрне сорадыгызмы? Дөреслектә Мин сезнең матурлыгыгызга һәм кыяфәтегезгә карамам, бәлки сезнең йөрәгегезгә һәм ниятегезгә карармын, һәм алар белән Минем ризалыгымны алыгыз”.

**12- Аллаһы Тәгалә боера:**

“Йә, Аллаһыга иман китергән бәндәләр! Чын курку белән Аллаһыдан куркыгыз һәм мөселман булмыйча үлмәгез. Белегез, гыйлемсез гамәл җимешсез агач кебек. Гамәлсез гыйлем, керешсез ук кебек. Зәкятьсез гамәл һәм гыйлем, ташка утырткан тоз кебек. Ахмакларда булган гыйлем, хайваннарда булган кыйммәтле ташлар кебек. Каты йөрәкле кешенең мисалы, суда эремәс таш кебек. Вәгазьне теләмәгән кешене вәгазьләү, мәетләр алдына куелган ашлар һәм сулар кебек .Хәрәм малдан зәкят чыгару, сидек белән пычрактан юыну кебек. Зәкятсез намаз, җансыз рух кебек. Тәүбәсез гамәл, нигезсез бина кебек. Аллаһның мәкеренә имин булам дип уйламагыз, хәсрәттә булган каумнар гына алай уйлый.

**13- Аллаһы Тәгалә боера:**

“Йә, Адәм баласы! Һәр мал, Минем малым, син Минем колым. Ни өчен сиңа Минем малым синдә ашаганнан, кулланганнан, киенгәннән, сәдака биргәннән калачак маллардан башка, калганына һәм артыгына Минем ачуым төшә. Йә, Адәм баласы! Син өч өлештән торасың: берсе үзеңнеке, берсе Минеке һәм берсе синең белән Минем арасындагы. Минем өлешем булганы - ул синең рухых, синең өлешең булганы – ул - гамәлең, безнең арабыздагы өлеш-ул синең догаң булганы һәм Миннән аларга җавап кайтаруым. Йә, Адәм баласы! Әгәр башлыкларыгыз үз тәкәбберлеге һәм җәберлеге аркасында җәһәннәм утына керсәләр, калганнары гөнаһлары аркасында керерләр: галимнәр хөсидләре өчен, Коръән укучылар гафләтләре өчен, сатучылар хыянәтләре өчен, һөнәрчеләр ялганнары өчен, гыйбадәт кылучылар рия өчен, байлар тәккәберлеге һәм зәкят чыгармау өчен, фәкыйрьләр алдаулары өчен һәм кайда җәннәткә керергә теләгән кешеләр?”.

***14- Аллаһы Тәгалә боера:***

“Йә, Адәм баласы! Бел, синең әҗәлең өметләнгәннәреннән көлә, Минем язмышым синең кыланганнарыңнан көлә, синең өлешең теләгәннәреңнән көлә.

Йөрәгеңне төзәт һәм Минем язмыш һәм тәкъдиргә тапшыр. Чөнки Мин ризыгыңны бүлгәләп һәм үлчәп куйдым, аның язмышы да үзгәрми, ахирәт өчен бөтен гамәлеңне тапшыр, чөнки бу дөнья ризыгыңны, синнән башка берсе дә ашамас. Без сезнең барыгызга да бу дөнья тормыш өлешен бүлдек, һәм кайберегезнең дәрәҗәсен күтәрдек бер берегезнең хаҗәтләрен үтәр өчен, тәкәбберләнер өчен түгел. Мин бу дөньяга әмер иттем: ”Йә, дөнья! Минем әүлияләремә буш итеп күрен, алар Минем белән очрашуны теләсеннәр”. Йә, Адәм баласы! Бел, үлем җитәр, сиңа ошамаса да һәм синең турында ялган сөйләнер, син теләмәсәң дә. Аллаһы Тәгаләнең хөкемнәренә сабыр ит, чөнки син монда вакытлыча җибәрелгәнсең. Иртән торганда Мине мактап тор. Төннәр буе йолдызлар югалганчы Миңа тәсбихләреңне әйт. Йә, Адәм баласы! Сезнең дә, Минем дә теләкләр бар, ләкин Мин теләгәннәрем генә хасил булачак. Кем Минем теләгемә риза булса, Мин аңарга ул теләгәннәрен бирермен. Йә, кешеләр! Кем изге гамәлләре белән Миңа омтылса, Мине таныр. Кем Мине таныса Мине теләр. Кем Мине теләсә Мине табарга юл эзләр. Кем Мине табарга юл эзләсә, табар. Мине тапкан кеше Мине исенә төшерер. Кем Мине исенә төшерсә, Мине онытмас һәм шуны Мин дә исемә төшерермен һәм бер кайчан да онытмам. Йә, Адәм баласы! Синең гамәлең ихласлы булмас дүрт үлемне татып карамыйча. Беренчесе кызыл үлем, икенчесе ак үлем, өченчесе сары үлем һәм дүртенчесе кара үлем. Кызыл үлем - түземлектә һәм сабырлыкта .Ак үлем - озын дәшми яшәүдә. Сары үлем-озын игътибар. Кара үлем - үзеңнең нәфсеңә каршы килүдә. Кем кеше ләрне Аллаһы Тәгалә юлыннан өздерсә, аңа каты газабы булачак”.

**15- Аллаһы Тәгалә боера:**

“Йә, Адәм баласы! Төне - көне синең янында сүзләреңне һәм эшләреңне язып баручы фәрештәләрем бар. **Җ**ир аның өстендә кылган начар гамәлләреңә шаһит булып тора. Күккә менгән синең гөнаһларыңа ул шаһиттыр. Синең гамәлләреңне күреп кояш белән ай аларга шаһиттыр. Бөтен нәрсәне белүче Аллаһ сиңа шаһит булуы җитәр. Ул Аллаһ сине күкрәгеңдәге хәтерләрне дә, нәфсеңнең вәсвәсәләрен дә белүче. Йә, Адәм баласы! Гомерең кыска, син үләчәксең һәм сиңа үлем дә җитәр аның турында уйлап шөгыльләнер өчен. Йә, Адәм баласы! Хәләл

сиңа тамчы - тамчы килер, хәрәм сиңа туктаусыз агып килер. Кем хәрәмнән тормышын саф кылса, аның дине саф булыр”.

**16- Аллаһы Тәгалә боера:**

“Йә, Адәм баласы! Дөнья тормышы өчен шатланма, син мәңгелек түгелсең. Аллаһы Тәгалә итагатенә сабыр бул,чөнки Ул һәр бер авырлыкта ярдәмче булып тора. Фәкыйрьлегеңне кайгыртма, ул синең өстеңдә тамга түгел. Өметеңне Аллаһ рәхмәтеннән өзмә, дөреслектә Аллаһ Рәхимле һәм гафу итүче. Гөнаһ эшләүчеләрнең җәһәннәм утына алып барган эшләрен ташла. Бу дөньяда гына кадерле, ахирәттә хурлы байлыкка шатланма. Фәкыйрьләрне бу дөньяда хөрмәтләмиләр, теге дөньяда хөрмәт күрсәтәләр, ахирәт яхшырак һәм мәңге калучыдыр.

Бел- фәкыйрьлектән курку, Аллаһы турында начар уйлаудандыр. Йә, Адәм баласы! Синнән дога, Миннән кабул итү. Синнән начарлыклардан гафу үтенү, Миннән гафу итү. Синнән тәүбә, Миннән кабул. Синнән нигъмәтләремә шөкер, Миннән ризыгыңны арттыру. Синнән авырлыкка сабыр итү, Миннән ярдәм бирү. Гыйлемне эзлә, ул сине җәннәт юлына бастырыр…”.

**17- Аллаһы Тәгалә боера:**

“Кем яхшылыкны кешеләр мактау сүзләрен ишетү өчен эшләсә, таш тау башына суны ташып, йомшартыр өчен сибеп маташкан кеше кебек була һәм аңарда ару - талудан башка бер нәрсә ала алмас эшләре дә кабул ителмәс, су белән ташны йомшартып булмаган кебек. Йә, Адәм баласы! Бел, Мин Үзем өчен генә чын күңеле белән кылган гамәлләрне кабул итәм, шуңа күрә ихласлы кешеләр уңышка ирешер. Йә, Адәм баласы! Килеп кергән фәкыйрьлекне күрсәң, әйт: “Изгеләрнең гадәттәге булган хәлләренә рәхим итегез!” Килеп кергән байлыкны күрсәң, әйт: “Ул газапка ирештерүче гөнаһлар! ”Сиңа кунаклар килмәвен белсәң әйт: “Таш белән сөрелгән Шайтаннан Аллаһы Тәгаләгә сыгынам”. Йә, Адәм баласы! Һәр байлык Минем малым, син Минем колым. Кунак - Минем сиңа илчем, әгәр Минем малымны, Мин сиңа җибәргән илчемнән тыйсаң, нигъмәтләремнән мәхрүм калачагыңнан син курыкмыйсың мени? Ризык миннән булса, синнән шөкер булсын. Аның файдасы сиңа тиеп тора,син Мин биргән нигъмәтләр өчен Мине бер дә мактамыйсың. Йә, Адәм баласы! Сезнең өстегездә

өч бурыч бар: булган байлыгыгыздан зәкят малын чыгару, туганнарың һәм остазларың белән яхшы мөгамәләдә булырга, гаиләңне һәм кунакларыңны намаз укырга өндәргә. Әгәр син шул Мин кушкан вазыйфаларны үтәмәсәң, Мин сине бөтен галәмгә гыйбрәт итеп ясармын. Йә, Адәм баласы! Әгәр күршеңнең хакын, гаиләңнең хакы кебек үтәмәсәң, мин сиңа карамасмын, сиңа рәхмәтемне дә бирмим һәм догаңа җавап та кайтармам. Йә, Адәм баласы! Син үзең кебек башка мәхлүккә тәвәкәлләмә. Мин сине аның колы итеп эшләрмен. Син бер кем алдында да тәкәббер булма, мин барыгызны да бер тамчы судан яраттым, сырт белән күкрәк арасында һәм сидек чыккан урыннан чыгардым. Мин сиңа хәрәм кылган нәрсәләргә карама, кабердә корт иң беренче синең күзләреңне ашыйлар. Бел, һәр бер карашың һәм һәр бер мәхәббәтең өчен хисапланырсың. Иртәгә Минем алдымда синең урының нинди булачагын истә тот. Мин сине бер мизгелгә дә калдырмам һәм Мин күңелдәге булган нәрсәгезне дә белеп торучы".

**18- Аллаһы Тәгалә боера:**

"Йә, Адәм баласы! Миңа хезмәт итегез. Мин колларымны сезгә хезмәт иттерермен. Син бит гомерең буе күпме Миңа гөнаһ эшләгәнеңне белмисең һәм тагы да алда күпме әле эшләрсең. Мине искә төшерергә онытма, чөнки Мин теләгән нәрсәне эшләүчедер. Син хур кол буларак Мин Бөек Раббың буларак, Миңа гыйбадәтеңне кыл. Йә, Адәм баласы! Әгәр Адәм балалары арасында синең яраткан якыннарың, дусларың һәм кардәшләрең, синең гөнаһ эшләгән исләреңне сизсәләр һәм синең турында Мин белгән нәрсәләрне белсәләр, синең белән һич утырмаслар иде һәм синең яныңа якын да килмәсләр иде. Ничек соң алай була? Гөнаһларың көннән көн арта бара. ләкин әниең сине тудырганнан алып, гомерең көннән көн кыскара бара. Йә, Адәм баласы! Көймәсе уртага бүленеп каты җил белән дулкынланган диңгез уртасында бер тактага тотынып калганның хәле синең хәлеңнән авыррак түгел. Син гөнаһлы булганыңа шикләнмә һәм гамәлең котылырга җитмәүдән саклан. Йә, Адәм баласы! Мин сиңа мохтаҗ булмасам да,сиңа яхшылык белән карыйм һәм синең гөнаһыңа күз ябам. Синең Миндә хаҗәтең булып та, миңа гөнаһларың белән каршы киләсең. Йә, Адәм баласы! Кайчанга хәтлем фани булган бу дөньяда урыныңны урнаштырып һәм мәңге булган теге дөнья урыныңны җимереп йөрерсең. Йә, Адәм баласы! Минем

мәхлүкләрем белән идарә итәсең, үзең аларның ачуыннан каты куркасың. Минем белән карышып Миңа каршы киләсең, һәм Миннән курыкмыйсың. Минем көчем аларның ачуларына караганда катырак. Йә, Адәм баласы! Әгәр синең өчен җир һәм күк әһелләре Миннән гафу сорасалар, сиңа үзеңнең кылган гөнаһларыңа еларга гына калыр иде, чөнки син белмисең нинди хәлеңдә үләрсең, ничек Минем белән очрашырсың…”.

**19- Аллаһы Тәгалә боера:**

“Йә, Адәм баласы! Кулыңны йөрәгеңә куеп дөресен уйлап, сиңа иң сөекле кирәкле нәрсәне, кешеләргә дә сөйлә. Йә, Адәм баласы! Синең тәнең көчсез, телең җиңел, йөрәгең каты. Йә, Адәм баласы! Мин синең әгъзаларыңны яратыр алдыннан, аларга ризыкларын да яраттым. Йә, Адәм баласы! Синең гомерең үлем белән бетәр һәм ул сиңа килгәнче изге эшләр эшлә. Йә, Адәм баласы! Әгәр Мин сине телсез итеп яратсам, син сөйләргә теләр идең. Әгәр Мин сине сукыр итеп яратсам, син һәр нәрсәне күрергә теләр идең. Әгәр Мин сине саңгырау итеп яратсам, син ишетергә теләр идең. Шуның өчен Мин сиңа биргән нигъмәтләрнең кадерен белеп, Миңа шөкер ит, көферлек кылма һәм син Минем хозурыма кайтачаксың. Йә, Адәм баласы! Мин сиңа язган һәр бер нәрсә, сине таләп итеп,сиңа ирешеп тора. Йә, Адәм баласы! Минем исемем белән ялган ант әйтмә, кем ант итеп ялганласа, Мин аны утка кертермен. Йә, Адәм баласы! Әгәр Минем ризыгымны ашасаң, артыннан итагать итәргә ашык. Йә, Адәм баласы! Син иртәгәге ризыкны Миннән бүген сорама, Мин бит синең иртәгәге гамәлләремне эшләтмим. Йә, Адәм баласы! Мин синнән аз булган гамәлеңә ризамын, син Минем күп биргән ризыгыма риза түгелсең. Йә, Адәм баласы! Әгәр Мин бу дөнья нигъмәтләрен Минем колларымнан берсенә бирергә теләсәм, Мин аларны пәйгамбәрләрнең кулына бирер идем. Алар Минем колларымны итагатькә өндәр өчен һәм Минем боерганнарны үтәр өчен. Йә, Адәм баласы! Сиңа үлем төшкәнче, үзең өчен изгелекләр эшләп тор. Гөнаһларыңның җәзасызлыгы белән алданма, аның киләчәк газабы бик зур. Сине тулы дөнья тормышың һәм бетмәс теләкләрең тәүбә кылудан аермасын. Син вакытында кылмаган тәүбәң өчен үкенерсең, ләкин үкенүең бер файда китермәс. Йә, Адәм баласы! Әгәр син Мин сине ризыкландырган малымнан, Минем хакымны чыгармасаң һәм фәкыйрьләргә

аларның хакларын бирүдән баш тартма, синнән җәберләп бөтен малыңны талап алган солтанны җибәрермен. Йә, Адәм баласы! Әгәр Минем рәхмәтемне теләсәң, Миңа итагатьле бул. Әгәр Минем газабымнан курыксаң, гөнаһлардан саклан. Йә, Адәм баласы! Әгәр синең алдыңда дөнья бөтен матурлыгы белән килеп басса, син үлемне искә төшер. Әгәр гөнаһларың арта башласа, тәүбәне искә төшер. Әгәр мал кәсебе белән шөгыльләнсәң, хисапны искә төшер. Әгәр ашарга утырсаң ачны искә төшер. Әгәр синең нәфесең көчсезне рәнҗетергә өндәсә, син Аллаһ Тәгаләнең кодрәтен исеңә төшер, ул сиңа биргән көчне кире алып,көчсезенә бирә ала. Әгәр синең өстеңә бәла-казалар төшсә, син Миннән ярдәм сорап, әйт: “Бөек һәм Олуг булган Аллаһыдан башка һич кемдә көч-күәт юк”. Әгәр чирләсәң сәдака бирү белән шифа сора. Әгәр сиңа кайгы төшсә әйт: ”Дөреслектә без Аллаһы Тәгаләнеке һәм аңарга кире кайтырбыз”.

**20- Аллаһы Тәгалә боера:**

“Йә, кешеләр! Уйлый белү белән, һич бер нәрсәне чагыштырып булмый. Кешегә зарар китергән нәрсәне юлдан алу, иң олы тәкъвалык. Тәрбиянең иң олысы намус. Тәүбәдән олырак шәфәгәтче юк. Гыйлемнән яхшырак гыйбадәт юк. Намазның иң изгесе куркып уку. Бәхеткә иң кирәге тәүфыйк. Чибәрнең иң матуры акыл. Һәм наданлыктан катырак кайгы юк. Йә, адәм баласы! Миңа гыйбадәт кылуга вакыт тапсаң, Мин үзеңне байлык, йортыңны ризык һәм тәнеңне рәхәтлек белән тутырырмын. Мине зикер итүдә гафил булма, әгәр гафләттә итсәң, Мин үзеңне мохтаҗлык, тәнеңне авырлык һәм насаб, күңелеңне кайгы һәм хәсрәт белән тутырырмын. Йә, Адәм баласы! Миңа итагать итүдә сиңа җитешлек ярдәм итә. Уңышлыгың фаразларны үтәргә ярдәм итә. Әмма Минем ризыгымны ашап гөнаһ эшлисең .Минем нигъмәтләремдә яшәдең һәм кулландың, бизәндең җитешлектә. Ләкин Мине онытып башканы искә төшердең, шуның өчен Миңа шөкер итмәдең”.

**21- Аллаһы Тәгалә боера:**

“Йә, Адәм баласы! Миңа зарлану килешмәсә дә, син Миңа зарланасың. Син Мине онытасың, ул Миңа лаек булмаса да. Күпме Минем нигъмәтләремне инкяр итәрсең, Мин үземнең колыма золымлык эшләмәсәм дә? Күпме Минем китабымны кичектерерсең, Мин бит син башкара алмаган нәрсәне йөкләмим?

Кайсы вакытка кадәр Минем белән кызыксынмассың, Мин синең белән кызыксынсам да? Кайсы вакытка кадәр мине мактамассың, Миннән башка сине кем дә дәваламас һәм Миңа һич тиңдәш юк. Күпме тагы тәкъдиремә риза булмассың, ләкин ул сиңа хәерлерәк. Мине тормыш шулай эшләде һәм шуны күрсәтте, дип Мине онытып әйтерсең. Мин сезгә яңгырларны жибәргәннән соң сез, безгә шул йолдыз һәм давыл яңгырлар яудырды, дип әйтерсез. Ул Мин йолдызларны һәм давылны яраттым. Һәм Мин үз рәхмәтем белән яңгырны урынлаштырып, үлчәп, кирәкле итеп яудыручы. Йә, Адәм баласы! Кем өч көнлек ризыгын тапса һәм Миңа шөкер итмәсә, Минем нигъмәтемне исәпкә алмады. Кем байлыгыннан зәкят чыгармаса, китабымны исәпкә алмады. Намаз вакыты житеп, аны эшегезне бүлеп кылмасагыз, Миннән гафил булдыгыз.

**22- Аллаһы Тәгалә боера:**

“Йә, Адәм баласы! Мин боерган нәрсәләрне эшлә, мин тыйган нәрсәләрдән тыел, шунда мин сиңа мәңгелек гомерне бирермен. Йә, Адәм баласы! Әгәр синең сүзең матур булып гамәлең ямьсез булса, син мөнафыйкларның башлыгы. Син иң хәсрәтлеләрдән булырсың. Синең тышкы кыяфәтең матур булып, эчеңдә начарлык булса, Аллаһы Тәгаләне һәм мөселманнарны алдарга тырышканнар, үзләре дә сизмичә, үзләрен генә алдыйлар. Йә, Адәм баласы! Кем Минем олылыгымнан куркып итагать итсә, көндәге эшләрен бүлеп Мине искә төшерсә һәм Минем ризалыгым өчен генә шәһвәтеннән тыелса җәннәтемә керер. Йә, Адәм баласы! Мосафирны кунак ит, фәкыйрьне куандыр, туганнарың белән аралаш, бәладә булучыга мәрхәмәтлек кыл, ятимнәрне сыйла һәм аларга үз баласын сөйгән әти кебек бул, тол хатынга үз хатыныңа шәфкатьле ир кебек бул. Кемдә бу сыйфатлар булса, Миңа дога кылса җавап кайтарырмын һәм сораган нәрсәсен бирермен”.

**23- Аллаһы Тәгалә боерды:**

“Йә, китаб әһелләре! Ни өчен сез эшләмәгән нәрсәләрне сөйлисез? Ни өчен үзегез тыелмаган нәрсәләрдән тыясыз? Ни өчен үзегез эшләмәгән нәрсәләргә өндисез? Ни өчен үзегез ашап бетерә алмаган нәрсәләрне җыясыз? Сездә үлемнән иминлек бармы? Сездә җәһәннәм утыннан коткара торган нәрсә бармы? Яки сезнең җәннәткә керүегез шиксезме? Әллә сезне Аллаһның нигъмәтләре иркәләде

һәм сезгә карата яхшылыгы бозды, шуның өчен сез Рәхмәтле Раббыбыздан курыкмыйсызмы? Яки сезне теләкләрегез алдадымы? Сезнең исәнлегегез сезне алдамасын, чөнки аның көннәре билгеләнгән һәм сулышлары беткән. Һәм үзегезнең серләрегезне дә Аллаһы Тәгаләдән яшерә алмыйсыз. Ул бөтен яшерен нәрсәләрне белеп торучы. Йә, акыл ияләре! Аллаһыдан куркыгыз, бәлки сез уңышка ирешерсез. Кулдагы булган нәрсәләрне алдагы булачак нәрсәләргә файдаланыгыз. Йә, Адәм баласы! Сине әниең тудырганнан бирле гомереңне туздырып йөрисең. Йә, Адәм баласы! Дөреслектә син бу дөньяның ләззәтенә алданучы балга эләгеп калган чебен кебек, ул тыпырчынган саен тагы да ныграк бата, Һәм утын кебек кеше файдасына гына гомереңне яндырып бетермә”.

**24- Аллаһы Тәгалә боера:**

Йә, Адәм баласы! **Җ**әннәт ачкычы һәм аңа алып баручы булган яхшы гамәлгә омтылыгыз. **Җ**әһәннәм ачкычы һәм аңа алып баручы булган начар гамәлдән сакланыгыз. Йә,Адәм баласы! Бел, бу дөнья ышанычлы йорт түгел,шуңа күрә аның тормышы да ышанычлы түгел.Тәнең җиргә керер. **Җ**ыйган байлыгың варисларыңа булыр,аның белән башкалар файдаланырлар, ләкин аның хисабы,газабы һәм үкенече сиңа калыр. Кабердә сиңа гамәлең юлдаш булыр. Сине хисаплаганчы, үз-үзеңне тикшер. Миңа итагатьлек ит һәм гөнаһ эшләрдән саклан. Минем биргәнемә риза бул һәм шөкер итүчеләрдән бул. Йә, Адәм баласы! Кем көлә-көлә гөнаһ эшләсә, ул җәһәннәм утына елый - елый кертелер. Йә, Адәм баласы! Күпме байлар фәкыйрь булырга теләрләр, әгәр алар җәһәннәм утына елый - елый кертелсәләр. Кем гөнаһы турында уйлап Миннән куркып күз яшьләре түксә, ул җәннәт нигъмәтләренә елмаеп кертелер. Күпме байлар фәкыйрьлек теләрләр хөкем көнендә. Күпме җәберләүчеләрне үлем хурлады. Күпме ләззәтне үлем тәмсезләде. Күпме нигъмәте белән шатланучыны үлем хәсрәтләде. Күпме куанычтан соң озын кайгы төшерде. Йә, Адәм баласы! Әгәр хайваннар үлем турында сез белгән нәрсәләрне белсәләр, алар ашау һәм эчүдән тукталып, ачтан һәм сусаудан үлерләр иде. Йә, Адәм баласы! Үлемнең ачысын һәм авырлыгын үлчәп булмый, ләкин әгәр белсәң, төннәр буе йоклый алмассың һәм көннәр буе үзеңә урын табалмассың. Әмма киләчәге аңардан да катырак. Йә, Адәм баласы! Ахирәттә ирешәчәк нигъмәтләргә куан һәм синнән узып киткән нигъмәтләре өчен

үкен. Дөньяви нәрсәләр килүгә куанма һәм синнән узып киткәнгә кайгырма. Йә, Адәм баласы! Яшьлегең белән алданма, күпме яшьләр кабергә китеп бардылар. Йә, Адәм баласы! Мин сине туфрактан яраттым, җиргә кайтарачакмын һәм җирдән кубарачакмын. Шуңа күрә дөньялыкны калдыр һәм үлемеңне сәламлә. Бел, әгәр Мин колымны сөйсәм, аңардан дөньялыкны читләштерермен, хезмәтен мәңгелек өчен кулландырырмын, дөньяның кимчелекләрен күрсәтермен һәм сакланыр. Ул җәннәт әһелләренең эшен эшләп, аннары Үз рәхмәтем илә җәннәткә кертермен. Әгәр Мин сөймәсәм, Мин аны дөньялык белән шөгыльләндерермен һәм эшен эшләттерермен. Ул җәһәннәм әһелләреннән булыр, аннары утка кертермен. Йә, Адәм баласы! Һәр гомер үтәчәк, озын булса да. Тормыш күләгә кебек, аз гына саклый да китеп бара һәм кире кайтмый. Йә, Адәм баласы! Мин сине бар итүче, сине ризыкландыручы. Мин сиңа гомер бирүче, сине үтерүче, сине тергезүче һәм хисап алучы. Әгәр яхшылык кылсаң, савабын күрерсең. Начарлык кылсаң, җәзасын күрерсең. Син бит үзеңә файда да,зарар да, үлем дә, гомер дә, кубаруны да китерә алмыйсың. Йә, Адәм баласы! Миңа итагать һәм хезмәт ит. Ризыгыңны кайгыртма. Мин аны сиңа җитәрлек итеп бирдем һәм син нәрсә турында да борчылма. Мин аңа җиткердем. Йә, Адәм баласы! Ничек син аңлый һәм белә алмаган әмернең хөкемен алып барасың, ул эшләмәгән эшнең савабын алалмау кебек. Йә, Адәм баласы! Кемнең юлы үлем булса, ничек ул тормышка шат. Кемнең өе кабер булса, ничек бу дөньядагы йортына сөенә. Йә, Адәм баласы! Аз гына ризык булып, син аңарга шөкер итсәң, ул синең өчен хәерлерәк, күп ризык булып та, синең аңа шөкер итмәвең. Йә, Адәм баласы! Иң яхшы мал теге дөнья өчен тараткан мал һәм иң начар мал бу дөнья өчен тараткан мал. Шуңа күрә синең әҗәлең җиткәнче, үзеңә яхшылыкны сайла. Йә, Адәм баласы! Кем кайгыда булса, Мин кайгыны ишетүче. Кем ялангач булса, Мин генә киендерүче. Куркуда булганның, Мин куркуыннан имин калдыручы. Ачның, Мин генә тамагын туйдыручы. Әгәр Минем колым Миңа буйсына һәм әмеремне үтәсә, Мин аңа эшен җиңеләйтермен, әзерен ныгытырмын һәм күңелен ачырмын. Йә, Муса! Кем ярлы һәм ятимнәр маллары белән баеса, Мин аны бу дөньяда ярлы кылырмын һәм ахирәттә каты газап белән газаплармын. Кем тормышын фәкыйрьләр өчен төзесә, Мин аны хурлармын. Кем өен ярлы һәм ятим куллары

белән төзесә, Мин аның тормышын һәм бинасын җимереп ялкынлы утта яшәтермен. Бу алдагы сәхифәләрдә бар. Муса һәм Ибраһим сәхифәләрендә. Бөтен галәмнәргә тәрбияче булган Аллаһка хәмед-мактауларыбыз. Мөхәммәдкә салават - сәламнәребез булсын. Һәм аның гаиләсенә булсын.”

**Изге гамәл эзеннән**

Сезнең иң хәерлеләрегез
Коръәнне өйрәнгән һәм
башкаларга да өйрәткәннәрегездер.

*Хәзрәти Мөхәммәдһиссәлам.*

“Мәдрәсә” сүзе гарәп телендә “мәктәп, училище” мәгънәсен белдерә. Ул мәчет эчендәге бер бүлмәдә яки мәчет янындагы бинада урнашкан. Дин һәм фикъһе өйрәтелә торган әлеге уку йортлары X гасырда хәлифәлекнең Көнчыгыш өлешендә -Урта Азиядә һәм Хорасанда барлыкка килә. Аларда мөселман культы хезмәткәрләре-мәчетләр өчен имамнар, казыйлар (шәригать буенча хөкем итүчеләр), шундый ук уку йортлары өчен мөдәррисләр (мәдрәсә җитәкчесе, фикъһ- ислам динендә хокук гыйлеме белгече, ислам дине шәригатендәге әдәп, әхлак кагыйдәләрен һәм хокук белемен яхшы белүче), хәлфәләр һәм дәүләт аппараты өчен хезмәткәрләр әзерләнгән. Мәдрәсә программасына Коръәнне үзләштерү һәм ятлау, аның тәфсирен, хәдисләрне, шәригатьне, гарәп теленең грамматикасын һәм риторикасын өйрәнү кертелгән.

Коръән, Коръән –Кәрим гарәпчә “яттан уку, яттан сөйләү” мәгънәсен аңлата. Ул Ислам фәлсәфәсендә изге дип танылган китап. Анда Ислам кануннары, тәгълиматы, хокук һәм әхлак мәсьәләләре үз чагылышын тапкан.

Коръән 114 сүрәдән гыйбарәт: һәр сүрә аятьләргә бүленгән, аларның саны 6204 яисә 6239 тирәсендә.

Ислам дөньясында башта Коръәнне башка мөселман халыклары телләренә тәрҗемә итү тыелган булып, аны фәкать аңлату ягъни тәфсир кылу гына мөмкин булган.

1787 елда Петербург Фәннәр академиясе типографиясендә, патшабикә Екатерина П-нең махсус фәрманы белән, Коръәннең тулы гарәпчә басмасы нәшер ителә.XIX гасыр башларында Коръән -Кәрим Казанда басыла башлый.

1790 елда озак еллар Казан гимназияләрендә директор булып эшләгән һәм аларда Шәрык телләрен укытуның тарафдары  М.И.Веревкин Коръәннең рус телендә тәрҗемәсен бастырып чыгарган.

1792 елда атаклы тәрҗемәче А.Колмаков Петербургта Коръәннең Дж.Сэйлинең инглиз телендәге хезмәте нигезендә, рус телендәге тәрҗемәсен нәшер итә.

1824 елда шагыйрь Александр Сергеевич Пушкин “Подражание Корану” исемле китабын бастырып чыгара.Анда Коръәнгә ияреп язылган шигырьләр тупланган. Шигырьләренә язган искәрмәләрендә А.С.Пушкин Коръәндә күп кенә хакыйкатьләр көчле һәм шигъри рәвештә язылганлыгын әйтә. Аны бигрәк тә Коръәннең көйле булуы, әдәби телдә язылуы, анда тасвирланган шигъри күренешләрнең байлыгы кызыксындырган.

“Подражание Корану” китабында А.С.Пушкин әдәбият-сәнгать өлкәсендә иң беренчеләрдән Коръәни Кәримнең 33 сүрәсен шигъри алым белән тәфсир кыла.

Мәсәлән,”Бәкарә” сүрәсенең 256 нчы аятендәге “Ләә икрәәһә фиддини (Ислам динендә көчләү, мәҗбүрләү юк) ”дигән фикерне А.С.Пушкин түбәндәгечә аңлата:

С небесной книги
Список дан
Тебе, пророк,не для строптивых;
Спокойно возвещай Коран,
Не понуждая нечестивых!

Ә инде адәм баласын алдап, фәкыйрьләр исәбенә дөнья малы туплаучыларга фани дөнья вә кыямәт газапларын вәгъдә иткән Раббымызның фарызларына пәйгамбәребезнең: “Адәм баласының корсагын туфрактан башка нәрсә тутырмас”,-дигән хәдисен шагыйрь:

Торгуясь совестью бледной нищетою,
Не сыпь своих даров расчетливой рукою:
Щедрота полная угодна небесам.
В день грозного суда, подобно ниве тучной,
О сеятель благополучный,
Сторцею воздаст она твоим трудам,-

диган шигъри юллар белән аңлата һәм рәнҗетелгәннәрне, көчсезләрне яклый.

Коръән сүрәләренең әдәби телдә язылуы һәм аның тәҗвид моңы белән укылуы  А.С.Пушкинны әсир иткән.

В пещере тайной,
в день гоненья
Читал я сладостный Коран,-

дип яза шагыйрь.

Пушкин бабасының атасы- Ганнибал- мөселман булган. Шагыйрьнең борынгы әби- бабалары милади 615 нче елда Мәккә кяферләренең ээзәрлекләүләреннән качып Эфиопиягә күчәләр. Абрам Петрович Ганнибал (мөселманнар аны Ибраһим дип атаган) Абиссиниянең Лагона шәһәрендә мөселман диненә инанучылар гаиләсендә дөньяга килә. Малай бик матур булганга, аны урлап Төркиягә коллыкка сатарга алып киләләр. Мөселман малаен Русиянең илчесе сатып ала һәм патша ПетрI-гә бүләк итә. Патша аңа “Ибраһим (Абрам) Петрович Ганнибал” исемен биргән.Русиядә күренекле дәүләт эшлеклеләре, хәрби хезмәткәрләр булган Ганнибал нәселе үзләренең мөселман икәнлекләрен онытмаганнар. Нәселдәге шушы тылсымлы бәйләнеш шагыйрьне Коръәнгә гашыйк иткәндер дә инде,аның да күңелен Ислам нуры җылыткандыр.

Хиҗазда кайсыбер шәехләргә ышаныч китереп суфыйлыкта рөхсәте булса да Ишмөхәммәтнең мөрид (рухани җитәкчесенең эзеннән баручы) тәрбияләүгә теләге булмый һәм ул, Әл-Әзһәр мәдрәсәсен тәмамлагач, Бохарадагы Күгелдаш, Сәмәркандтагы Хуҗа Әхрар мәдрәсәләрендә шәкертләрне Коръән уку серләренә төшендерә.1783 елда Казан шәһәренең беренче мәчете каршындагы мәдрәсәдә укучыларга сабак бирә.Әлеге мәчет Екатерина П-нең махсус указы белән салына, ул Казан шәһәренең тарихына, халык язмышына аерылгысыз рәвештә бәйле, ул үзендә бик борынгы хатирәләрне саклый. Әлеге мәдрәсәдә эшләгән чорында Ишмөхәммәт хаҗи Коръәнне матур итеп көйләп яттан укуы, матур язуы һәм тирән гыйлеме белән зур абруй казана.

”Коръән уку гыйлемендә остаз булган кебек, тавышы чиктән тыш гүзәл, башкаруы дөрес, язуы тиңдәшсез яхшы булганга, бу мәмләкәт олуглары

хозурында мәртәбәсе югары булган”,-дип яза Ризаэтдин Фәхретдин “Асар” хезмәтендә.

Бу мәчеттә соңыннан, 1849-1889 елларда, имам булып Шиһабетдин Мәрҗәни хезмәт итә. Әлеге көндә Казандагы ул мәчет “Мәрҗәни” исемен йөртә.

Ишмөхәммәт хаҗи, Казан шәһәренең байлар мәхәлләсендәге мәчет (бүгенгедә -Апанай мәчете) каршындагы мәдрәсәдә укыткannan соң акбабаларының туган төбәге Кибәк авылы мәдрәсәсендә шәкертләрне Коръәнне дөрес һәм матур итеп көйләп укырга өйрәтә.

Кибәктән Ишмөхәммәт хаҗи, мәдрәсә җитәкчесе Габделгалләм хәзрәтнең чакыруы буенча, Иж-Бубый авылы мәдрәсәсенә (бүгенге көндә Татарстанның Әгерҗе районына карый) эшкә килә. Ул дәвердә Вятка губернасының Сарапул өязе составындагы Иж-Бубый авылында ачылган мәктәп соңыннан мәдрәсә итеп үзгәртелә.Вакыт үтү белән әлеге уку йорты мөселман мәгърифәтчелегендә бик кирәкле үзәккә әверелә. Белемгә омтылган яшь егетләр, Русиядән генә түгел, Польшадан, Литвадан, Себердән, Төркстаннан бәләкәй генә авылдагы шушы мәдрәсәгә укырга киләләр. Уку 12 ел дәвам иткән. Программага алгебра, геометрия, тригонометрия, физика, биология, Русия һәм Шәрык тарихы, география, француз, рус, төрек, гарәп телләре кергән. Коръәнне өйрәнүгә, аны дөрес һәм матур итеп укуга аеруча нык игътибар бирелә.

Габделгалләм хәзрәтнең өлкән улы Габдулла Буби, атасы мәдрәсәсен тәмамлагач, аңа ярдәмче мулла булып урнаша. Ул мөселман гыйлемендәге яңа юнәлеш белән мавыга һәм үзе дә китаплар яза. Аның язуы буенча, мәдрәсә тарихында Коръәнне Ишмөхәммәт хаҗи кебек матур һәм дөрес итеп укыган, аны шәкертләр күңеленә үтеп керерлек итеп аңлаткан, искиткеч матур каллиграфияле мөгаллим моңа кадәр булмаган.

Шиһабетдин Мәрҗәнинең “Мөстәфадел-әхбар фи әхвәли Казан вә Болгар” әсәреннән өзек китерү урынлы булыр. Анда Ишмөхәммәт мөгаллимнең эшчәнлеге бәян ителә.

“Таһир хәзрәт.Тумышы белән Сембер өлкәсе Кормыш өязенең Бәтракс карьясеннән. Казан иленә килгәч, башта Мәчкәрәдә мелла Мөхәммәдрәхим ахун мәдрәсәсендә белем ала, Саба карьясендә мелла Габдерәшид бине Габделкадыйр

хозурында да укый. Ахырда Ишмөхәммәд бине әл Кибәкидән Коръәнне яттан уку гыйлемен ала һәм аның фатихасы белән Малмыж өязенең Адай карьясендә имам хатыйб була һәм Коръәнне дөрес һәм күрмичә уку дәресләре бирә. Озак гомер сөреп күбәүләргә остаз булды.

Гадәттән тыш матур тавышлы, киң күкрәкле, озын буйлы кеше иде. Һәртөрле мәкамнәр белән укытты. Кайберсен хәрәмин көе, кайберсен коддыс көе дип атап, үзе дә төрле көйләр чыгара һәм шул көйләр белән укый иде. Әлеге көйләрдән максат- җыр-музыка калыбына салу һәм шәригатькә сыймаган көйләү түгел, ә матур тавыш белән җиренә җиткереп уку иде. Үзе Ишмөхәммәд хаҗиның шәкерте булса да, ә соңгысының укуы яхшы һәм тавышы матур булса да, мелла Таһирның өстенлеге һәм осталыгы ачык иде. Үзем аның шәкерте булмасам да, укуына гаять сокланучылардан һәм дә бик тә яратып тыңлаучылардан идем. Үзе: ”Башлангыч кыйраәтне Мәчкәрәдә Мөхәммәдрәхим ахуннан алдым. Соңыннан Ишмөхәммәд хаҗидан укыдым, ә ахырда Багдади хаҗидан гыйлем өстәдем. Хаҗи Багдади минем укуымны хуш күреп укыта иде”,-дип сөйли иде. Ләкин биргән иҗазәтнамәләрен фәкать Ишмөхәммәд хаҗига бәйләп яза иде,”-дип бәян итә Шиһабетдин Мәрҗәни. -“Ишмөхәммәднең шәкертләре: Таһир бине Сөбхан әл-Адайи, Габделлатыйф бине Сөбхан әл-Кыйрчый,Хәбибулла бине Габделваһаб әл-Чакмагышый, Таҗетдин бине Габдрәшид әл-Иштирәки, Тавабил бине Сабак әл-Йөгәмеши, Нурмөхәммәд бине Ибраһим әл –Казаный һ.б.”

***

1734-1744 елларда Сенатның обер-секретаре И.К.Кириллов тәкъдиме белән Башкортстанның көньяк-көнчыгыш чикләрендә ныгытмалар төзү өчен Оренбург экспедициясе оештырыла. Әлеге ныгытмалар системасы Урта Азия һәм Казахстанны Русиягә кушу өчен плацдарм хезмәтен үтәргә тиеш була. Чит илләр колллегиясе тәрҗемәчесе А.И.Тәвкилев Кирилловның ярдәмчесе итеп тәгаенләнә.1734 елның 10ноябрендә Оренбург экспедициясе Уфага килә. Составында 130 офицер, 3500 солдат, төрле һөнәр ияләре булган Оренбург экспедициясенә Башкортстанда ныгытмалар төзү бурычы куела. Унсигезенче гасырның 30-50 елларында 53 ныгытма, 40 форпост һәм редутка нигез салына. 1735-43 елларда Табын, Оренбург, Орск, Сорочинск, Верхнеяицк (хәзерге

Верхнеурал), Красный Яр(хәзерге Красноуфимск), Троицк ныгытмалары төзелә. Әлеге ныгытмалар, форпостларның күпчелеге төбәкнең көньяк, көньяк – көнчыгыш һәм көнчыгыш чикләрендә барлыкка килә. Аларны төзегәндә бик күп башкорт жирләре тартып алына. Әлеге хәл халыкта ризасызлык тудыра һәм төзелеш барган төбәкләрдә баш күтәрүләр, чуалышлар башлана. Аларны Оренбург губернаторы ярдәмчесе, каратель отряды башлыгы морза Тевкелев Алексей Иванович (христиан диненә күчкәнче Котлыәхмәт Тәвкилев исемендә йөрегән) рәхимсез рәвештә, аеруча вәхшилек белән бастыра, башкорт җирләрен көч белән тартып ала.Тарихтагы әлеге кайгылы көннәр башкорт халык иҗатында да чагылыш тапкан. Ахырына: “Язучы Шакирйән Нәгимян улы”, -дип куелган әлеге бәет Башкортстанның Әлшәй районы Ташлы авылында яшәгән Йомабикә Сәүбановада сакланган.

**Тәфтиләү бәете**

Тәвкилевнең җиренә куш буразна сызылган,
Башкортларның яше төшкән -Әхмәт морза бозылган.
Тәвкилевнең урманында озын икән агачы;
Озын сакал кара урыс-Әхмәт морза бабасы.
Алты йөздә алты аршин Әхмәт мырза амбары,
Петербурда бер (азгынга)Әхмәт мырза алданды,
Әхмәт морза киткән чакта акбузатка атланды.
Әхмәт морза бозылгач,Габит карак шатланды.
Әхмәт морзаның боланы йыл да мөгез арттыра,
Алты мыскал алтын-мәрҗән Әхмәт муенына тактыра.
Бикә әби солы сала өер-өер казларга,
Әхмәт морза маллары Габит кебек тазларга.
Әхмәт морза ашаганы кара тавык калҗасы,
Әхмәт морза бозылганда алдан керде марҗасы.
Тәвкилевнең җирендә быел уңган тарысы,
Әхмәт морза почмагында тора инде тәресе.
Өченче ел чия уңды, Әхмәт җыйды аксасын,
Быел килеп бигрәк уңды, инде Бикә юньләсен.

Тәвкилевнең җирендә бик уңган,ди,арышы,
Ислам диненә кермәскә Әхмәт морза карышты.
Әхмәт морзаның атлары үргә таба тартмый, ди,
Бу морзаның балалары гел кыз булгач артмый, ди.
Бикә әби амбар сала биек тауның башына,
Бу морзаны мендерделәр зур чиркәүнең башына.
Әхмәт морза киткән чакта карат җигеп киттеләр,
Бу морзаны кайтар, дип падишага җиттеләр.
Бикә әби асыраганы үрдәк белән каз әле,
Әхмәт кебек чукынмышка бу бәетләр аз әле.
Әхмәт морза язу яза, күрән икән карасы,
Бу морзаның нәселләре бозылдылар барысы.
Зирекле елга буйлары,кәкре-бөкре таллары,
Опекунга калды инде Әхмәт морза маллары.
Бикә әби тегермән кора Чәрмәсәннең буенда,
Утыз урыс җыелдылар Әхмәт морза туенда.
Әхмәт морза бу туның дөньялыкта кимәсләр.
Әхмәт морза бозылды бит,инде мөьмин димәсләр.
Әхмәт морза амбар яны,көн-төн өрә күк эте,
Бу морзага кермәде бит хәзрәтнең үгете.
Әхмәт морза болыны Зиреклекүл буенда,
Әхмәт морза бозылды бит Гыймай морза туенда.
Әхмәт морза амбарында алты чучка таптылар,
Әхмәт морзаның муенында тугыз тәре тактылар.
Тәфтиләүнең җирләре барсы да өчпочмак,
Әхмәт морза почмагында алтыны бар бер кочак.
Әхмәт морза атлары барысы да кан җирән,
Туймас булып йөргән идең,туйдыңмы инде,карт бирән.
Әхмәт морза чиннегендә себеркеләр шүрлеге,
Бу морзаның бозылуы-бар да чия шомлыгы.
Гөлсембикә шүрлегендә алтын-көмеш посуда,

Гөлсембикә, чыгып кара, Әхмәт кайтты басудан.

Зирекле каран агачы сирәкләнде кискәнгә,

Әхмәт морза бозылды бит ил каһәре төшкәнгә.

Унсигезенче гасырның икенче яртысыннан башлап ныгытмалар тирәсендә посад һәм бистәләр барлыкка килә, Оренбург, Троицк, Орск эчке һәм тышкы сәүдә үзәкләренә әверелә башлый. 1738 елның җәеннән Оренбург аша Көнчыгыш илләре белән караван сәүдәсе юлга салына. Игенчелекне үстерү максатында Урта Идел буеннан крестьяннарны күчерү, ныгытмалар тирәсенә отставкага чыккан солдатларны, драгуннарны, казакларны урнаштыру башлана. Элеккеге Ашкадар тоз пристане урынында 1766 елда Стәрлетамак шәһәре төзелә,ә 1787 елда урыс казаклары ныгытмасы нигезендә Чиләбе шәһәре барлыкка килә.

1797 елда губерна үзәге Уфадан Оренбургка, 1802 елда янә Уфага күчә,ә Оренбург хәрби губернатор резиденциясе булып кала.

Үзәге Оренбург шәһәре булган Оренбург өлкәсе төрки халыкларның бик борынгыдан бирле яшәү төбәге булып тора. Аның җирләре Төрки каганлык, Алтын Урда, Нугай Урдасы биләмәләренә кергән. Мөселманнарның анда күпләп күченә башлаулары 18 йөзнең икенче яртысына туры килә. Казан губернасыннан күченүчеләр исәбенә 1744 елда Каргалы бистәсенә нигез салына. Яңа Мәскәү юлы буйларына ясаклы татарлар урнаштырыла, йомышлы татарлар Оренбург казаклары гаскәренә хезмәткә билгеләнә.

Оренбург шәһәренә нигез салыну турында “Мөстәфадел-әхбар фи әхвәли Казан вә Болгар” әсәрендә Шиһабетдин Мәрҗәни түбәндәгеләрне яза:”Казан читендәге олы бер өлкәнең гүзәл, нык һәм сәүдә үзәге булган шәһәредер. 1734 елның азагында мирза Котлыгмөхәммәд бине Тәвәккәл бине Мәмәш бине Дәүләтмөхәммәд бине Уразмөхәммәд хан, Русия гаскәре белән килеп, бу шәһәрне төзетә.Рус дәүләтенә күп хезмәтләр күрсәтеп, ул генерал-майор дәрәҗәсенә ирешә. 1747 һәм 1753 елда исән булганлыгы мәгълүм. Хәзерге көнгә кадәр Оренбургта өч мәчет төзелде.

Беренче мәчет. Шәһәр эчендәге мәчетне князь Волховский гасырында Бохараның кәрван башы Иш төзеткән, аңа казна да күпмедер ярдәм иткән. Ишнең үзенә тарханлык дәрәҗәсе бирелгән. Бохарадан Оренбургка беренче тапкыр

кәрван башы булып килүче кеше-шушы кеше диләр. Углы –хаҗи Назарбай-Оренбургта Габдессәлам мөфтинең кызына өйләнеп,аның кияве булган.

Алмаш (Меновой) ярминкәсе мәчете. Мелла Сөләймән сүзләренә караганда, бу мәчет Оренбург төзелгәндә, мәликә Катерина вакытында казна ярдәме белән корыла. Аңа ике имам һәм ике мөәзин, бер хезмәтче билгеләнеп, барысына бер елга 105 сум акча бирелә.

Кәрвансарай мәчете. Оренбургтагы өченче мәчет “Кәрвансарай мәчете” дип йөртелә. 1843 елда башкортлардан акча җыеп төзелә. 1845 елда ачыла. Янында ике катлы бүлмәләрдән торган “Кәрвансарай” исемле бер бүлмәсе бар”.

Индия һәм Урта Азия дәүләтләре белән сәүдә итүне тагын да киңәйтү максатында Екатерина II идарә иткән дәвердә Оренбургтан дүрт чакрым читтә Алыш-биреш йорты –ярминкә төзелә башлый һәм ул 1758 елда тәмамлана. Бик зур мәйданны биләгән, таш кибетләр белән уратылып алынган әлеге төзелеш ныгытма рәвешендә була, анда 329 кибет эшләгән. Ел саен, август аеннан октябрьгә кадәр Алмаш (Меновой) ярминкәсенә Хива, Бохара, Индия һәм башка дәүләт сәүдәгәрләренең караваннары килгән. Ярминкәнең даны еракларга таралып товар әйләнеше дә арткач Алмаш ярминкәсе биләмәсендә таштан мәчет һәм чиркәү төзелә.

1789 елның 17 сентябрендә генерал- губернатор Аким Иванович Апухтин Ишмөхәммәт Заитовны Меновой (Алмаш) мәчетенең мөдәррисе итеп тәгаенли һәм мәчет эшчәнлеге өчен кирәкле кешеләрне билгеләүне аңа тапшыра. 1790 елда Ишмөхәммәт хаҗи Каргалы бистәсе мәчетенә мөдәррис итеп күчерелгәч Меновой мәчете мөдәррисе вазыйфасын Бөгелмә өязенең Баулы авылында туган Мансур улы Мөслим башкара.

Каргалы бистәсе заманында Оренбург төбәгенең мәшһүр мәгърифәт, мәдәният үзәге булган.Ул 1744 елда Оренбург шәһәреннән унсигез чакрым төньяктарак, Сакмар елгасына Каргалы суы койган урында төзелә башлый. Аны патшабикә рөхсәте белән Казан губернасыннан күчерелгән 200 ләп татар гаиләсе нигезли. Оренбургтагы “Меновой двор” һәм якындагы башка ярминкәләрдә тернәкләнеп киткән бистә сәүдәгәрләре Русия белән Урта Азия арасындагы сәүдәне җанландырып җибәрәләр. Заманында танылган шагыйрь, дин һәм

җәмәгать эшлеклесе, Каргалы бистәсендә туган Каргалый Әбелмәних Ишмөхәммәт хаҗиның шәкерте була. Соңыннан Каргалый Әбелмәних үз язмаларында мөгаллимен тирән ихтирам белән искә ала.

Чыгышлары белән дөнъяга билгеле Ислам дине үзәге булган Харәзмнән Ширнияз улы Ишнияз һәм Багдадтан Хәсән улы Вәлиятдин Ишмөхәммәт хаҗиның эшчәнлеген югары бәяләп:”Ул шәкертләргә генә түгел, ә безгә-мөгаллимнәргә дә-остаз булды,”-дип язалар истәлекләрендә.

1793 елда мөфти Мөхәммәтҗан Хөсәенов тәкъдиме белән Ишмөхәммәт хаҗи Оренбургта бай казах балалары өчен ачылган мәдрәсәдә шәкертләрне Коръән уку серләренә төшендерә башлый.

Ишмөхәммәтнең якташы,фикердәше Мөхәммәтҗан Хөсәенов Уфа өязенең Солтанай авылында туган.Каргалы авылы, Бохара, Кабул,Оренбург мәдрәсәләрендә югары дини белем ала һәм өстәмә рәвештә Ишмөхәммәт хаҗидан Коръәнне көйләп уку осталыгына өйрәнә.

Мөхәммәтҗан Хөсәенов 1785 елда Оренбург экпедициясенең ахуны булып тора һәм шул ук елны патшабикә фәрманы белән өлкәнең Беренче ахуны итеп билгеләнә.Ул Көньяк Уралда Екатерина П-нең эчке сәясәтен тормышка ашыруда булышлык итә,Русия империясенең Урта Азия, Көнчыгыш һәм Төньяк Кавказда үткәргән тышкы сәясәтендә актив катнаша.

1788 елның 22 сентябрендә Уфада ачылган Диния нәзарәтенә Екатерина П Мөхәммәтҗан Хөсәеновны мөфти итеп тәгаенли.

Мөфти Мөхәммәтҗан Хөсәенов, иң беренче чиратта, казах далаларында үз йогынтысын көчәйтергә теләп, экспедиция оештыра һәм үзе белән Ислам дөньясында зур абруй казанган Ишмөхәммәт хаҗины да ала. Юл күрсәтүчеләре Оренбургтагы чик буе комиссиясендә хезмәт итүче калмык Әнүр Салбай була. Алар далада,кышлаудан кышлауга күчеп, старшиналар, мулла һәм солтаннар белән очрашалар. Мөфти Мөхәммәтҗан үз вәгазьләрендә Ислам дине, Мөхәммәд пәйгамбәрнең сәяхәтләре турында сөйли,хәдисләр бәян итә, ә Ишмөхәммәт хаҗи Коръәнне яттан матур итеп укуы белән җыелган кешеләрне әсир итә.

Очрашып сөйләшүләр бик җиңелдән булмаса да уңышлы тәмамлана, урыс империясенең йогынтысы дала ягында сизелеп көчәя.

Икенче елны мөфти, үзенә юлдаш итеп Ишмөхәммәт хаҗины да алып, берничә тапкыр башкалага юл тота һәм ел ахырында, ниһаять, алар патша белән очрашу бәхетенә ирешәләр.

Диния нәзарәтенең дәрәҗәсе күтәрелә, хәзер ул мәхәллә халкы сайлаган дин әһелләренең гыйлем дәрәҗәсен тикшерү өчен имтиханнар үткәрә башлый һәм аның нәтиҗәсенә карап ахун, мөхтәсиб, хатыйб, имам, мөәзин исемнәре бирелә. Шул ук вакытта Уфа мөфтиятендә дин әһеленең педагогик квалификациясе дә билгеләнә һәм аңа, куелган таләпләргә җавап биргән очракта, “мөдәррис”, ”мөгаллим” дәрәҗәсе бирелә. Соңыннан аны губерна идарәсе раслый һәм дин әһеленә император указын бирә. Мөселманнар арасында империя сәясәтен үткәрүдә зур тырышлык күрсәткән дин әһелләрен медаль белән бүләкләү тәртибе кертелә.

1796 елда Екатерина II үлгәч тәхеткә Павел I утыра. Аның иң беренчеләрдән игълан ителгән “Дәүләтне губерналарга бүлү” турындагы указы нигезендә Уфа губернасы Оренбург губернасы итеп үзгәртелә. Губерна кантоннарга бүленә.

Диния нәзарәте тырышлыгы белән яңа мәктәпләр, мәдрәсәләр ачыла. Уфа мөфтиятенең дә абруе үсә,ул бөтен Русиягә таралган мөселманнар арасында шәригать кануннарының үтәлешен күзәтү астында тота, мөфтияттә даими рәвештә Оренбург, Казан, Саратов, Симбер губерналарыннан, Петербург һәм Мәскәү мөселманнарыннан килгән эшләр карала.

1825 елның 30 сентябрендә Оренбург ахуны Габдессәләм Габдрахимов Оренбург диния нәзарәтенең мөфтие тиеп тәгаенләнә.

Габдессәләм Габдрахимов 1765 елда Самара губернасының Бөгелмә өязе Габдрахман авылында туа. Башлангыч белемне туган авылы мәчете каршындагы мәдрәсәдә ала. Соңыннан Казан шәһәрендә Ишмөхәммәт хаҗи хезмәт иткән беренче мәхәллә мәдрәсәсе шәкерте була, Каргалы авылы һәм Оренбург шәһәре мәдрәсәләрендә укый. 1799 елда, Ишмөхәммәт хаҗи тәкъдиме һәм фатихасы белән, Оренбург җәмигъ мәчетенең имамы һәм мөдәррисе итеп тәгаенләнә.

Ул чорда остазыңнан фатиха алу зур ышаныч, дәрәҗә булып саналган һәм фатихалы кеше өчен һәр юл да ачык була.

Оренбург мөселманнары, казах ханнары арасында Габдессәләм Габдрахимовның абруе бик зур булган. Ханнар аның мәдрәсәсенә балаларын укырга җибәрәләр. Ул балалар, үсеп җитеп үзләре хан, солтан буларак, укытучылары янына төрле киңәшләр сорап килэләр.

1826 елның 15 февралендә Ишмөхәммәт хаҗи тәкъдиме белән Габдессәләм Габдрахимов мөфти итеп тәгаенләнә. Иң беренче эше итеп ул урындагы идарә органнарына төзеләчәк нәзарәт бинасының проектын тәкъдим итә.1829 елда яңа мөфти гражданлык актларын теркәүне тәртипкә сала, хәзер теркәү акча түләп башкарыла башлый һәм кергән акча махсус исәпкә туплана.

Мөфтинең үгетләве, тәкъдиме нәтиҗәсендә сәүдәгәр Мөкмин Таһиров 1830 елда Уфада 1 нче җәмигъ мәчетен төзи.Аны ачу тантанасына Ишмөхәммәт хаҗи да чакырыла.

Оренбург далаларында башланган остаз белән шәкертнең дуслыгы, хезмәттәшлеге 1840 елның 31 гыйваренә кадәр, Габдессәләм Габдрахимов бакыйлыкка күчкәнче, дәвам иткән.

## Туган җиргә ни җитә

Мөэмин-мөселман кеше
белемгә өйрәнеп,үзенең
белгәнен дин кардәшенә
өйрәтсә,шул сәдаканың
иң олысы булыр.

*Хәдис*

Җәяүләп хаҗ сәфәренә чыгып киткән Ишмөхәммәт, күп илләр, җирләр гизеп, егерме биш елдан соң гына туган авылы Күбәкнең туфрагына аяк баса.

“…Бу вакыт та яшьләре дә 47 булган икән.Фәкать бу юлы “скрипкачы Ишмөхәммәд” түгел, бәлки галим вә фазыйль Ишмөхәммәд хәзрәт буларак мәйданга чыккан. Байлыгы күп булып тегермән вә кярханәләр (остаханә, фабрика) салып,күп урман вә җирләргә ия булган,”-дип яза Риза Фәхретдин. (Асар. Казан, 2006.174б).

Ишмөхәммәт хаҗи, Фатыйма исемле кызга өйләнеп, гаилә кора.

Фатыйманың нәсел-нәсәбәсен ачыклар өчен Риза Фәхретдиннең “Асар” хезмәтеннән өзек китерик:

“Ишмөхәммәд бине Тукмөхәммәд (Тәмәк) бине Нияки бине Төнләч бине Сабырхуҗа бине Йәмаш бине Бәраш бине Байтөгәл бине Габдерразак бине Сардак бине Йәмин.

Тукмөхәммәд, Болгар шәһәреннән чыккан биләрдән булып, Дагыстан тарафына барып укыган һәм Тукмөхәммәд хафиз, Тукмөхәммәд шәех дип танылган. Ишмөхәммәд Малмыж өязендә Адай авылында XVII гасыр ахырларында аеруча шөһрәт казанган бер зат, Шәех баба дип танылган.

Уфа вилайәтендә Көбәк (Күбәк) авылында имам булган хаҗи Ишмөхәммәд бине Мөхәммәдзаһид каләме белән үзенең “Фәтави Һиндия” нөсхәсенә язганнан бер өзеге, бу урынга мөнәсәбәтле булганга, биредә китерелә:”Адай авылының Тәмәк Хафиз угылы Шәех баба булып,исеме Ишмөхәммәд.Аның угылы Балтай, Балтай кызы Ниязбикә исемле. Ниязбикә кызы Сәгадәт булып, Сәгадәтнең ике кызы булды. Берсенең исеме Хәдичә вә икенчесенең исеме Хәҗәр.Хәҗәрнең кызы Фатыйма бинте Гомәр булып,әл-хаҗ Мөхәммәд хатыны. Сәгадәт илә Хәсән икесе

бертуган вә Ниязбикә бинте Балтай балалары булып,аталары да Габдулла исемле зат иде".Ишмөхәммәд хаҗи бине Мөхәммәдзаһидның "әл-хаҗ Мөхәммәд" дигән кешесе үзедер." (Асар 40 б.).

Әйтергә кирәк,Ишмөхәммәт хаҗи күп кенә язмаларында үз исемен "Мөхәммәд" дип язган.

Күбәк килене Фатыйманың затлы нәселе белән тагы да тулырак танышу өчен Шиһабетдин Мәрҗәнинең "Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар" әсәренә мөрәҗәгать итеп бер өзек китерү урынлы булыр. (Казан.1989.297.298б.б.).

"Мелла Әбелхәсән Гали бине Исхак бине Габделкәрим бине Балтай бине Ишмөхәммәд бине Тәмәк бине Нияки бине Төнләчи бине Сабирхуҗа бине Ямаш бине Бараш бине Байтәвәккәл бине Габдерразак бине Сардак бине Ямин әл-Каргалый.Оренбургтагы беренче мәчеттә имам булып,соңыннан урыныннан алынып, Казан шәһәренә килеп гомер итә һәм 1259(1843) елда вафат була. Казанның яңа зиратына җирләнә, җеназасын мелла Сәгыйдь бине Хәмид укый. Кыз балаларыннан башка балалары булуы мәгълүм түгел. Казанда Коръәнне чагыштыру белән шөгыльләнә. Халык арасында "Каргалы мәхдүме" дип танылган була. Югарыда китерелгән нәсел-нәсәбен үзе ачыклап төзи.Бу хакта мелла Мөхәммәдшәрифкә язган хатында болай ди:"Нәсел-ыру һәм бабаларыбыз хакындагы мәсьәләне үзебез белүебезчә, хосусан, хөрмәтле атабыздан һәм бабаларыбыздан ишетүебезчә, Сезгә белдерәбез. Хәзрәтегезгә сер түгел, атабыз Каргалыда агач мәчеттә байтак еллар имам булып, 1216(1801) елда, хәмәлнең унсигезенче көнендә вафат. Халык арасында "Көмешче Исхак хәзрәт" дип танылган, мәшһүр остаз. Мәшһүр мелла Габдеррахман хәзрәт, атабыз мәдрәсәсендә торып, гыйлем алып, аның кызына өйләнеп, кияве булды. Мәшһүр мәхдүм хаҗи Хабибулла,мелла Гатаулла, мелла Хәйрулла әлеге тутабыздан тудылар. Кабере Каргалыда.

Атабызның әткәсе-мелла Габделкәрим."Шәехгәрәй хәзрәт"дип танылган. Ул Каргалыга беренче күчеп килгән кешеләрдән 11.(17…)елның рамазан аенда вафат булып, Каргалыда җирләнгән. Бохарага барып "Җәһрия" тарикасындагы ишан Әмлага кереп, анда унсигез көн торып, иҗазәт (рөхсәт кагәзе) алып Каргалыга кайткан. Анда ханәка ябып, яраннар тәрбияләгән. Мелла Балтай һәм аның әткәсе

Ишмөхәммәд шәех кабере-Адай авылында. Мелла Әбелхәсәннең атасы, Хисаметдин бине Шәрәфетдин әл-Болгари тарихына караганда, Тукмөхәммәд булган. Әмма үзебезнең шәҗәрәдә Тәмәк икәнлеге билгеле.Тәмәк Нияки углы-изге Болгардан чыккан Чыңгыз хан биләреннән. Кошыбыз-күчкән, агачыбыз-карагай,тамгабыз болай:Х…”.

Әлеге өзектә очраган “би”сүзенең мәгънәсен хәтеребезгә төшерик. Би(бәк,бәй) русларның кенәз дәрәҗәсенә тиң, ул төрки халыкларда ыруг- кабилә башлыклары, соңрак эре аксөякләр титулы. Алтын Урда һәм татар ханлыкларында олыс, өлкә идарәчеләре дәрәҗәсе, хан диваны әгъзасы. Би дәрәҗәсенә нәселле аксөякләр-морзалар билгеләнгән.

Фатыйманың туган ягы -Малмыж өязенең Адай авылы 1780-1920 елларда Вятка губернасының административ- территориаль бүленеш берәмлеге, үзәге-Малмыж шәһәре. 1780 елга кадәр Казан губернасы биләмәсенә кергән төбәк. СССРны районлаштыру барышында бетерелә, биләмәсе Киров өлкәсенә һәм өлешчә Татарстанга керә. Адай авылы бүгенге көндә Татарстанның Кукмара районына карый. Вятка елгасының уң кушылдыгы Бөре буендагы Адай 1678 елдан ук тарихта билгеле авыл.

Янә “Асар” га күз салыйк: ”Ишмөхәммәднең балалары Мөхәммәдлатыйф, Габделлатыйф, Габделҗәббар, Маһитаб һәм башкалар. Бер кызы Әмирхан угылы Габделгани ахун никахында. Икенче кызы Маһитаб, Шаһкол (Шакул) фамилиясеннән бер затка никахланып, Мәликә исемле кызны дөньяга китергән. Мәликә исә кенәз Сәлимгәрәй Әлмаксудыйга кияүгә бирелгән. Мөхәмммәтлатыйф исемле угылы Күбәк авылында имам вә ахун булган,”- дип яза Риза Фәхретдин.

Ишмөхәммәт хаҗиның тагы да ике улы бар- Гатаулла һәм Абдулҗәлил. Гатаулла бик яшьли-тугыз яшендә (1809-1819) мәрхүм була, Абдулҗәлил Күбәк авылы мәчетендә өлкән мулла, мөгаллим вазыйфасын башкара.

1797 елда ахун дәрәҗәсенә лаек булган Ишмөхәммәт хаҗи кайткач Күбәк мәчетенең имамы һәм мөдәррисе итеп тәгаенләнә. Иң беренче эше итеп үз исәбенә мәдрәсә өчен аерым бина төзетә башлый, ә ул әзер булганчы шәкертләрен өендә укыта. Аңардан сабак алырга күрше-тирә авыллардан да киләләр.

Ишмөхәммәт мөгаллим дәресләрен яңача алып барыр булган, гади, аңлаешлы итеп аңлаткан, шәкертләр дүрт-биш айда укырга-язарга өйрәнгәннәр.

Коръәнне яттан белгән Ишмөхәммәт хаҗи шәкертләрен Коръәнне дөрес һәм матур итеп көйләп укырга гына түгел, ә аның телен, стилен һәм терминологиясен дә өйрәткән. Ул Коръән-Кәримдә очраган терминнарның (мәсәлән, ”хәниф”, ”бәшәр”, ”адәм”, ”бәнү адәм” һ.б.) һәрберсенә дә аерым күренеш, мәгънә салынганлыгына басым ясый, Коръәндәге һәр аерым сүзне дә бары тик контекста гына өйрәнү зарурлыгын аңлата.

1831 елның 23 декабрендә Күбәк авылының җомга мәчете “җәмигъ мәчете” итеп үзгәртелгәч тә аның имамы, мөдәррисе итеп янә ахун Ишмөхәммәт хаҗи сайлана һәм тәгаенләнә.

Ислам тәгълиматен таратудагы хезмәте, мөселманнар арасында патша хөкүмәтенең сәясәтен үткәрүдәге эшчәнлеге өчен ахун,хаҗи Ишмөхәммәт Заитов югары даирәләрнең Мактау Аттестатларына лаек була, ә 1833 елның 30 октябрендә патша указы нигезендә дин әһелләренә бирелә торган иң югары бүләк-Көмеш медаль, язулы Анна лентасы белән бүләкләнә. Гомеренең соңгы елларында патша хөкүмәтенең Бронза медаленә лаек була.(Башкортстан дәүләт үзәк тарих архивы. Фонд И -295 .яз.4.эш 5940).

Ишмөхәммәт хаҗи авылдашларына, якташларына дини йолаларны дөрес итеп башкаруда да ярдәмләшә, дөньяви мәшәкатьләргә дә вакыт таба тынгысыз җан иясе-Идәш елгасында су тегермәне корып җибәрә. Тегермәнгә килүчеләрдән алына торган бер өлеш онны Ишмөхәммәт хаҗи ярлы яшәгән авылдашларына биреп барыр булган.

Язуы - каллиграфиясе ифрат гүзәл булган Ишмөхәммәт хаҗи шәмаил эшли торган остаханә дә ачып җибәрә.Шәмаил-бизәп язылган дога, аять, изге сүз. Ул алтын язулы хәрефләр белән яктырып, гарәп язуының сәнгатьчә камиллеге белән балкып, нур чәчеп тора һәм рухи дөньяны, төрле ышануларны чагылдыра. Шәмаилләрнең кайчан, каян һәм ничек барлыкка килүе сер пәрдәсе артына яшеренгән. Халык аларны “аятелкөрси”,”дога” дип тә атап йөртә. Мөселманнар өчен изге саналган урыннарның рәсеме төшерелгән, төрле гөнаһлардан һәм явыз көчләрдән саклаучы “изге язулар”һәм догалар язылган бу шәмаилләрнең тамыры

халыкның мәҗүсилек чорыннан ук килә .Ә инде борынгы Болгарда Ислам дине кабул ителгәч, шәмаилләрдәге язулар Коръәннең төрле аятьләрен, аерым сүрәләрен аңлатуга йөз тота. Халык иҗаты үсә барган саен, чорга бәйле рәвештә, шәмаилләрдә бүтән төсмерләр дә чагылыш таба бара, хәрефләренең билгеле бер төзелешенә табигать күренешләрен, халыкның матурлыкка һәм камиллеккә омтылуын, рухи идеалларын чагылдырган бизәкләр һәм сурәт –рәсемнәр пәйда була. Аларда чәчәк рәсемнәре, борынгы Болгар һәм Казан, Уфа символларын белдергән рәсемнәр, авыл мәчете сурәте - халыкка якын булган гадәти күренешләр өстенлек иткән.

Ишмөхәммәт хаҗи остаханәсендә эшләнгән шәмаилләр сыйфат ягыннан бик югары була һәм алар мөселман халыклары яшәгән бик күп төбәкләргә-Казан, Уфа, Оренбург, Казахстан, Урта Азия якларына таралган.

Ишмөхәммәтнең язылган догалары халык авыз иҗатында да чагылыш тапкан. Нәселенең чыгышы белән Күбәк авылыннан булган, ә картлыгында Алан авылында яшәгән Хәбибә Маннурова үзе иҗат иткән мөнәҗәттә:

Юл буенча укып килдем,
Ишмә сызган догасын.
Тәкъдиргә шулай язгач,
Ничек аны бозасың,- дип язган. Мөнәҗәттәге “Ишмә” исеме “Ишмөхәммәт” исеме белән бәйле. Әлеге исемнең халык телендә байтак кына фонетик үзгәрешләргә дучар ителеп: Ишмөхәммәт –Ишми, Ишмә, Ишмүк, Ишмәт формасында кулланылуы гадәти күренеш. Мәсәлән “Бикмөхәммәт” исеме - Бикмәй, Бикмүш, Бикмәт, Бишмәт дип тә әйтелгән.

Күбәк һәм Таулар авылларын салкын җилләрдән сакларга теләгәндәй бөгәрләнеп яткан Илбай тавы итәгендә безнең көннәргә “Ахун тугае” исеме белән килеп ирешкән төбәк бар. Табигатьнең матур да һәм бераз серле дә шушы урынына якын гына Уба сырты калкып тора, әрәмәлекләрендә борынгыда тамырланган карлыганнар әле дә татлы җимешләрен бирәләр.

Уба үзендә нииндидер сер саклыйдыр сыман, чөнки борынгыда, гадәттә, Уба ата-бабалар җирләнгән изге урын булып исәпләнгән һәм кешеләр анда килеп акбабалары рухына дога кылганнар.

Убадан ерак та түгел, Илбай тавы куенынннан агып чыккан чишмә ягында, Ишмөхәммәт хаҗиның умарталыгы булган, якында гына Тарлау басу җәйрәп яткан. (“Тарлау”-болын яки урман уртасындагы аерым басу мәгънәсен аңлата).

Әлеге җирләргә, урманнарга Ишмөхәммәтнең ата-бабалары 1707 елдан ук хуҗа булганнар.

Бу тарафта безнең көннәрдә “Хөбәйбә тавы” дип аталган төбәк бар. Заманында анда җир җиләге, чия, кызыл карлыган мул булган,сәламәтлек өчен файдалы үләннәр дә күп үскән. Кубәктә яшәүче Хөбәйбә әби җәйләрен әлеге тау буйларыннан, урман - яланнан җиләк- җимеш, сихәтле үлән җыяр булган. Көннәр, төннәр җылы,матур торганда Хөбәйбә әби, авылга кайтып тормыйча, урманда гына куна калган.

Көннәрдән берендә ул югала. Эзли торгач авылдашлары аның җансыз гәүдәсен әлеге тау башыннан табалар. Шушы хәлдән соң “Хөбәйбә тавы”атамасы халык теленә керә.

Үткәнгә күз салыйк: Заитның өч улы булган: Ишмөхәммәт, Баязит һәм Әлмөхәммәт. Хөбәйбә - Әлмөхәммәтнең өлкән кызы. Баксаң, Хөбәйбә әби бер дә чит - яр җирләрдә җиләк-җимеш җыймаган икән-үз акбабаларының аяк эзләре сакланган газиз җирләрне гизгән ул һәм шунда мәңгелеккә күзен дә йомган.

Ишмөхәммәт хаҗи җирләренең күршесендә Шәхмәй Смаилов (Исмәгыйлов) биләмәсе булган. Аның җир алу турындагы килешү кәгазе Башкортстан дәүләт үзәк тарих архивында (Ф.10.1 нче язма.Эш-1278.13б.) саклана. Шул документтан өзек китерик:

“…лете 1740 марта 24 дня Уфимского уезда Казанской дороги Канлинской волости башкирцы, а именно деревни Сабаевой Сюлюк Сюлюков, Ишим Князев, Умир Якупов, Юнус Булатов, деревни Кубяковой Айдан Атиев с тов.будучи в Уфе дали сию тое же Казанской дороги Енейской волости башкирцам, а именно, деревня…Сосновой Шахмию Смаилову… в том припустили мы Сюлюк и Ишим с товарищи на вотчинную свою землю”.

Документ - килешүдә исемләнгән Шәхмәй Смаилов безнең тарафларга әлеге Татарстанның Балтач районы Сосна авылыннан күченеп килгән һәм азмы-күпме көн күргән төбәк бүгенгедә “Смәлән”,”Шәхмәй” исемнәре белән килеп ирешкән.

Алга китеп шуны әйтеп үтик: илдә Столыпинның аграр реформасы башлангач отруб һәм хуторларга бүленергә рөхсәт ителә.

Ишмөхәммәт хаҗиның нәсел дәвамчысы Хәләфетдин дә борынгыда акбабалары җире булган төбәктән 40 гектар җир алып шунда иген игә башлый. Күбәк һәм Тугай авыллары арасындагы бу урын бүген дә “Хәләф җире”дип атала.

***

Гомерен, гыйлемен Ислам диненә, иленә һәм халкына хезмәт итүгә багышлаган, мөселманнарга Коръән серләрен ачарга булышлык иткән һәм күп шәкертләрнең остазы булган Ишмөхәммәт хаҗи картайган көнендә бик авыр хәлдә кала-Тарлау басуны өч вотчинник һәм 43 припущенник рөхсәтсез басып алалар, урманнары да читләргә китә, мал-мөлкәте дә тарала.

Гомеренең соңгы еллары ничек кенә авыр булмасын, Ишмөхәммәт хаҗи элеккечә үк ачык һәм йомшак күңелле, һәр сүзеннән гыйлем байлыгы сизелеп торган акыл иясе, абруйлы дин әһеле, остаз булып калган.

Үзенең яраткан бәндәсенә Алла, сынар өчен,байлыкны да, авырлыкны да бирер, дип юкка әйтмиләр инде.

Инде картайган әтисенең авыр хәлен күреп, белеп торган улы Мөхәммәтлатыйф, яклау, ярдәм сорап, Оренбург-Самара генерал- губернаторына рапорт язарга мәҗбүр була. (Әлеге хат-рапорт Башкортостан дәүләт үзәк тарих архивында саклана.Фонд И-295,язма 4,№ 637).Әмма югары даирәләрдән, буш сүзләрдән гайре, юньле ярдәм күренми.

Бездә элек-электән үк кеше кешегә һәм иленә көчле, гайрәтле чагында гына кирәк булган,күрәсең.

**Сүз ахыры яки яшәүнең дәвамы**

Таң ата да кояш чыга,
Кояшлы бездә һәр көн.
Кояш белән сәлам юллыйм,
Әссәламегаләйкем!

*Госман Садә*

Ишмөхәммәт хаҗиның кабер ташы югалгач улы яңаны куя. Аңа:”Хаҗи Ишмөхәммәд Заидов,вафат булды 95 яшендә,1 февраль, 1841 елда, яздым мин Габделлатыйф Ишмөхәммәд угылы 1870 ел,3 сентябрьдә”,-дип язылган.

Әлеге юлларны укыгач сорау туа: 1795 елда Оренбург губернасы Бәләбәй өязенең Күбәк авылында үткәрелгән ревизия (җанисәп) язмасында Ишмөхәммәткә 43 яшь дип күрсәтелгән, ягъни ул 1752 елда туган булып чыга.1816 елдагы җанисәптә ул 1753 елгы булып күренә.1834 елда уздырылган җанисәп вакытында Ишмөхәммәткә 80 яшь дип язылган, ягъни 1754 елда туган. Ә Габделлатыйф куйган таштагы язу буенча Ишмөхәммәт 1746 елда туган булып чыга.(1841 ел-95яшь=1746 ел).Баласының үз әтисе турында язганы дөрес булыр дигән уйга нигезләнеп Ишмөхәммәт Заитовның туган елын 1746 ел дип билгелик. Бакыйлыкка күчкән вакыты төгәл билгеле -1841 елның 1 феврале.

Ни хәл итмәк кирәк, адәм баласы бу дөньяларга мизгел өчен генә килә дә, вакыты үткәч, мәңгелеккә күчә. Кеше үлгәч аңардан ни кала соң? Пәйгамбәребез с.болай дигән: ”Әгәр берәү вафат итсә, аның гамәл дәфтәре ябыла. Аңа фәкать өч нәрсәдән савап килеп торачак: садакаи җариядән, файдалы гыйлемнән, игелекле баладан”.

Садакаи җария ул, башка хәдисләрдә аңлатылганча, төзелгән күпер, мәчет, мәдрәсә һ.б. Чөнки алардан бар кеше дә файдалана, куллана. Шуның өчен андый гамәлләрнең савабы да олы икәнлеге ассызыкланган.

Шулай ук кешегә вафатыннан соң да савап китерә торган гамәл –ул аннан мирас итеп калган гыйлемдер. Аның әҗере зур икәнлеге турында Мөслим Әбү Дауд һәм Тирмизи риваять иткән хәдисләрдә Рәсүл Әкрам с.шулай дигән: ”Кем ки Һидаятька чакырса,аңа аның эзеннән барганнарга язылган күләмдә савап язылып, аларныкыннан һич кенә дә киметмәс”.

Савап китерүче гамәлләрнең тагы берсе-салих-ата-анасы, акбабалары хакына дога кылучы, аларның эш-гамәлен үзе яшәгән заманда дәвам итүче бала.

Әгәр дә адәм баласы бу дөньяда шундый эшләрне кылган булса, вафатларыннан соң да аны һәммәсе изге теләк белән искә төшерер, догада исемнәре искә алыныр, аның нәселен дәвам итүченең эш-гамәлләре рәвешендә рухы безнең көннәргә яңадан кайтыр.

Халкыбызның хәтер сандыгында ата-бабаларыбыздан калган бер бәет саклана-“Картлык бәете”дип атала ул.

Үтте китте яшь гомерләр искән жил тик,
Картлык миңа килеп җитте,ай-һай, тиз бик;
Яшьлек гөлләр сулды бит,чәчкә койды,
Көз көнендә коры калган үләннәр тик.
Түгел яшьлек, картлыгым да бетәр әле,
Бу дөньядан бөтенләйгә китәр әле;
Барлыгы кайдан килсә,шунда китәр,
Калганы да җирдә ятып череп бетәр.
Ләкин мәңге калыр минем һаман җаным,
Кара җирдә чересә дә калган тәнем;
Бер вакыт фәрман булыр тәңребездән
Кушылсын дип тәнем белән газиз җаным.
Менә шунда саф яшьлек миңа килер,
Яшь вә яңа тән белән җан кушылыр;
Мәңге бетмәс гөлләр шунда атыр чәчкә,
Мәңге бетмәс яшьлек менә шунда булыр.

Чыннан да, яшәештә, буыннар бәйләнешендә тылсымлы бағланыш, дәвамчылык бардыр ул. Пушкин бер дә юктан гына Коръәнгә багышлап шигырьләр язмаган- аның мөселман булган акбабаларының Коръәнне Изге дип танулары шагыйрьгә дә күчкән, бәйләнгән һәм аның җанындагы уй-тойгылары әсәрләрендә чагылган да инде.

Татарстанның Әгерже районы Кыдырлы авылында борынгыда бертуган Әхмәтшакир белән Шиһабетдин Заитовлар яшәгән. Шиһабетдин җәяүләп хаҗга

да барып кайткан. Бертуган Заитовлар Чучкан авылы янындагы җирләрне сатып алып Минзәлә өязендәге Югары Саклау авылыннан җирсез берничә гаиләне күчереп утырткан һәм үз акчаларына кызыл кирпечтән, шул чор өчен бик күркәм манаралы мәчет салдырганнар. Без кызыл әләмнәр күтәреп коммунистлар җитәкчелегендә социализмнан коммунизмга китеп барган чорда, әлеге мәчет хәрабә хәленә килә: түбәсе дә, түшәме дә, ишек-тәрәзәләре дә юкка чыга аның-бары тик стеналары гына утырып кала. Мәчет кенә түгел, юлсыз, мәктәпсез, кибетсез калгач Саклау авылы үзе дә тарала- анда җәйләрен биш-алты кеше генә кайтып яшәп китәр була.

Әхмәтшакир белән Шиһабетдиннең нәселе дәвамчысы, Казан шәһәрендә яшәгән Шамил Заитов бабаларының ядкәре булган Саклаудагы мәчетне торгызырга алына һәм озак та үтми яңартылган мәчеттә моңлы азан тавышы яңгырый.

Саклау мәчетенә яңадан “җан өрергә” Шамил Заитовны беркем дә мәҗбүриләмәгән, ә аны әлеге изге гамәлгә буыннан буынга күчәр булган тылсымлы көч этәргәндер, эшкәрткәндер дә инде.

Ишмөхәммәт Заитовның туган авылы Күбәк белән иңгә-иң терәшеп торган Таулар авылында заманында дүрт мәчет булган. Илебездә коммунистлар хакимлеге урнашкач әлеге Алла йортлары халыкка хезмәт итүдән туктатылдылар, манаралары кисеп төшерелде, биналары хуҗалык ихтыяҗлары өчен кулланыла башлады. Шунсы гаҗәп, мәчет манарасын кисеп төшергән куштаннарның күбесенең артабангы язмышы бик аянычлы була, аларның нәселен дәвам итүчеләргә дә соңыннан кайгы бик еш килер булган. Алланың рәхмәте булган кебек рәнҗеше дә бар, күрәсең.

Мәчет манаралары сыкрап җиргә ауган шомлы елларда халкыбыз тарафыннан иҗат ителгән бер бәет белән танышып үтик.”Манара бәете” дип атала ул.

И манара,синең аең бик
Еракта ялтырый,
И манара, син аугачтын, барча
Адәм калтырый.

Манара әйтә:”Әлвидагым, бүген мине кисәләр”,

“Әлвидагым, бәхил бул”,-дип,йомшак җилләр исәләр.

“Манара кисәләр”,-диеп дошманнар җыелдылар,

**Җ**ир йөзенә фәрештәләр саф-саф булып иңделәр.

Манара әйтә:”Кисәләр бит, авам, авам, тотыгыз!”

Мин аугачтын, һәр барчагыз”Вәл гасрый”укыгыз”.

Манараның тәрәзәсе бар да җиргә коелды,

Фәрештәләр, канат җәеп, саф-саф булып тезелде.

Борма - борма баскычларын алып кына куйдылар,

Борма саен фәрештәләр саф-саф булып кундылар.

И манара, син булмагач, барча кошлар таралды,

И манара, син булмагач, ислам дине таралды.

“Манараны кисәләр!”-ди бала-чага тавышы,

И манара, син булмагач, бетте азан тавышы.

И манара, күп заманнар әйтелгән иде азан,

Ходайның вәгъдәсе шулдыр, җитте ахыры заман.

Һавада болыт булмаса. җилләр дә исмәс иде,

Ходайдан әмер булмаса, ул да киселмәс иде.

И манара, син куелгач, әйттек синдә әлвидаг,

Инде хәзер син киселгәч,әйтик хәзер әлфирак.

И манара, син куелгач бөтен дөнья булды нур,

Инде безгә рәнҗеп китмә,шәһре рәхмәт, шәһре нур.

Әлвидаг әйтә алмадык синең актык көнеңдә,

Мине бүген кисәләр,дип,бар да килде күрергә.

Манара әйтә мәчеткә:”Бүген мине кисәләр”,

Төньягыннан искән җилләр: “Кисәләр!”-дип исәләр.

Манара әйтә:”Юк гөнаһым, кисмәгез, дим, кисмәгез,

Кыямәтләр җиткән көндә күп җаваплар бирерсез”.

Мәчет әйтә: “И манара, и минем михрабларым,

Әлвидаг,дип ишетегез, актыккы минутларым”.

Барча халык җыелганнар,бар да мәчет сүтәләр,

Мәчеттәге фәрештәләр тәкбир әйтеп китәләр.

Манара әйтә: “Актык көнем, бик ашыгып кисмәгез,

Минем турдан үткән чакта дога кылмый китмәгез”.

Биек булган манараны мөнафикъләр кисәләр,

Ахирәттә мөнафикъләр тәмугыга төшәләр.

И манара, күп заманнар яшәдең бу дөньяда,

Дошманнарга шатлык булды ошбу фани дөньяда.

Кая синдә шау-гөр килеп, намаз укыган чаклар,

Хуш - әлвидагыңны чәчеп, азан әйтелгән чаклар?

И манара, гүзәл идең, каршы идең кыйблага,

Ничә мең ел зикер-тәсбих әйткән идең Аллага.

Иртән торып тышка чыксам, азан тавышлары ишетәбез,

Азан тавышын ишетмәгәч, мәхрүм булып китәбез.

И манара, үзәгеңне кемнәр кисеп төшергән?

Аны кисеп төшергәндә җирләр, күкләр тетрәгән.

И манара, ишегалдың кемнәр себереп киткәннәр?

Төрле кошлар килеп сайрар,бик ямансу итәрләр.

Манараның бәрәкәте, нуры очты давылга,

Манараны кискән көннән бәрәкәт юк авылда.

Манараны кисәргә дип шатланып йөрерләр,

Йортына хуҗа булмады манара кисүчеләр.

И манара, ничә еллар син утырдың нур булып,

Сине кисеп төшерүчеләр йөри инде хур булып.

Илдәге соңгы чордагы үзгәрешләр нәтиҗәсендә мөселманнар яшәгән төбәкләрдә яңадан мәчетләр төзелеп азан моңы ишетелә башлады. 2008 елның апрелендә Таулар авылында да мәчет нигезенә беренче таш салынды һәм ноябрь аена ике манаралы мәшһүр мәчет төзелеп тә бетте. Ике катлы әлеге Алла йортын төзүгә мәхәллә халкы кулларыннан килгәнчә ярдәмләште, урындагы “Алга” хуҗалыгы да читтә калмады. Ә төп иганәче, мәчет төзүгә бик теләп алынучы Ишмөхәммәт хаҗи нәселенең дәвамчысы Әхмәт Вәлиәхмәт улы (әнисе- Рәзинә Гариф кызы)  Ишмөхәммәтов булды.

Ахун, мөдәррис, Ислам дине белгече һәм Коръәнне гаҗәеп матур итеп яттан көйләп укучы Коръән -хафиз Ишмөхәммәт хаҗи рухының аһәңе аның дәвамчысы төзеткән мәчет тарафларыннан ишетелгән азан тавышында да, Коръәннең илаһи моңында да тоемлана, ишетелә кебек.

Башкорт халкының үлемсез бәетендәге сүзләр тагы да искә төшә:

Менә шунда саф яшьлек миңа килер,

Яшь вә яңа тән белән җан кушылыр;

Мәңге бетмәс гөлләр шунда атыр чәчкә,

Мәңге бетмәс яшьлек менә шунда булыр.

Заманында Ислам күгендә йолдыз булып балкыган Ишмөхәммәт хаҗиның рухы да аның дәвамчысы Әхмәт Ишмөхәммәтов төзеткән мәчет сыйфатында, рухи яңарыш буларак, бүгенге көнебезгә, арабызга әйләнеп кайтты.

Һәм яши.

Сүз тәмам.

Үә гәләйкүм үә рахмәтулләәһи үә бәракәәтүһ.

1972.2014.

## Әдәбият исемлеге


-Р.Фәхретдин.Казан ханнары.Казан,1995.

-М.Юсупов.Шигабутдин Марджани.Казан,2005.

-Шиһабетдин Мәрҗәни.Мөстәфадел-әхбар фи әхвәли Казан вә Болгар.Казан,1989.

-Татар энциклопедия сүзлеге.Казан,2002.

-Ислам.Белешмә-сүзлек.Казан,1993.

-С.Синенко.Мусульманское духовное собрание.Уфа, 2008.

-Башҡорт халыҡ иҗады.Өфө,1978.

-Азаматов Д.Д. Из истории Оренбургского магометанского собрания. Ватандаш.1997,3.

-Асфандияров А.З.Религиозная политика царизма в Башкирии в период феодализма. /Башкирский край/Вып.1 Уфа,1991.

-Башкортостан: Краткая энциклопедия.Уфа,1996.

-Азаматов Д.Д.Оренбургское магометанское духовное собрание в конце XVII- в.Уфа,1999.

-Валеева М.Г.Из истории Центрального духовного управления мусульман БАССР.Уфа,1994.

-Давыдова Н.М.,Хазиев В.Г.Фонд Оренбургского магометанского духовного собрания.Вып.1.Уфа,1973.

-Жуковский И.Краткое и статистическое описание Оренбургской губернии.СП б.,1880.

-Журнал Оренбургского муфтия. 1790.

-Ислам в Российской империи. М., 2001.

-Ислам на территории бывшей Российской империи. Энц. словарь. Вып. 1, 2. М. 1998, 1999.

-Кульшарипов М.М.Открытие духовного управления мусульман в Уфе. Уфа, 1988.

-Мажитов Н.А., Султанова А.Н. История Башкортостана. Уфа, 1994.

-Руденко С.И.Башкиры.Уфа, 2007.

-Рычков П.И.История Оренбургская.Уфа, 2001.

-Губернаторы Оренбургского края.Оренбург, 1999.

-Фархшатов М.Н. Оренбургское магометанское духовное собрание и школьное просвещение тюркских народов дореволюционной Башкирии. Уфа, 1991.

-Гайса Хөсәенов.Ризаитдин бин Фәхретдин.Өфө, 1997.

**Ишмөхәммәт Заитовның эшчәнлеге яктыртылган язмалар**

-Шиһабетдин Мәрҗәни.Мөстәфадел әхбәр фи әхвәли Казан вә Болгар.Казан, 1989.

-Ризаэтдин Фәхретдинов.Асар.Оренбург, 1904.

-Ринат Мөхәммәдиев.”Татар дөньясы” газетасы.

Мәскәү, 2008,12.

-Фәнүр Гыйльманов .Ике манаралы мәчет.Уфа,2008.

-Идрис Сәетгәрәев.”Кызыл таң” газетасы.Уфа, 2012.

22 ноябрь.

-Гали Гатауллин .Фәрештәләр канат какты.

Казан, 2012.

-Эльвира Әсадуллина “Өмет” газетасы.2013,

14 апрель.

## Автор турында белешмә

Гали Шайслам улы Гатауллин 1948 елда Башкортстанның Бүздәк районы Таулар авылында туган. Урта мәктәптә укыган чорында җәйләрен комбайнер ярдәмчесе, укуын тәмамлагач бер ел шофер булып эшли. Казан дәүләт университетында һәм Башкорт дәүләт университетында белем ала, чит тел буларак гарәп телен өйрәнә. Соңыннан туган районының Якуп, Тугай, Таулар мәктәпләрендә, ”Кызыл таң” гәзите, ”Һәнәк” журналы редакцияләрендә эшли.

Чәчмә һәм юмористик әсәрләре, афоризмнары Башкортстан һәм Татарстан матбугатларында, чит ил басмаларында басылып чыкты. Берничә ел “Өмет” гәзитенең “Ялт-йолт”сатира-юмор кушымтасын алып барды.

Туган төбәген өйрәнүгә багышланган дистәдән артык китап нәшер итте, яшь һәм башлап язучыларның әсәрләрен басмаларга әзерләде.

Ике тапкыр “Өмет” гәзитенең, шулай ук “Һәнәк” журналының ел лауреаты булды. 2007-2008 елларда “Тулпар” журналы үткәргән хикәяләр конкурсында беренче урынны яулады. 2014 елда үткәрелгән республика крайны өйрәнүчеләр конкурсында җиңүче буларак П дәрәҗә Диплом белән бүләкләнде.

Гали Гатауллин Русия һәм Башкортстан язучылар берлеге әгъзасы.

**Эчтәлек**

-Җырлап-уйнап урадым,Күбәк авылы урамын………………….

-Ислам-яшәү рәвеше……………………………………………..

-Изге гамәл эзеннән …………………………………………

-Туган җиргә ни җитә…………………………………………

-Сүз ахыры яки яшәүнең дәвамы…………………..

-Әдәбият исемлеге…………………………………………………

-Ишмөхәммәт Заитовның эшчәнлеге

яктыртылган язмалар……………………………………………..

-Автор турында белешмә…………………………………..

Научно- популярное издание

Гатауллин Гали Шайсламович

# Жизнеописание Ишмухамеда хаджи

Религиозная и просветительская деятельность
Ишмухамеда Заитова

Книга издается в авторской редакции

Компьютерда җыйды:Валеева Ф.М.
Верстка ясаучы:
Корректоры:Гатауллин А.Г.